ПӘНҖЕШӘМБЕ
18 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 15 (5815)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Дингә каршы пропаганданы көчәйтик

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүне, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерүне Сталинчыл өченче бишьеллыкның төп политик бурычы итеп куйды. „Эчке бурычларыбыз ягыннан караганда эшнең үзәге хәзер тәрбия мәсьәләсенә, коммунистик тәрбия мәсьәләсенә, хезмәт ияләренең аңында капитализмның әле шул кадәр яшәүчән булган калдыкларын бетерү бурычына күчерелә“ **(Молотов).**

Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә, аларның аңында капитализм калдыкларын бетерүдә дингә каршы пропаганда мәсьәләсе гаят зур урын тота.

Марксизм-ленинизм күрсәткәнчә, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларының иң тирән эз калдырганы, иң яшәүчәне—дин, дини гореф-гадәтләр, бу калдыклар үзләрен тудырган сәбәпләр бетерелгәннән соң да әле кешеләрнең аңында тиз генә бетмиләр.

Җәмгыятнең иҗтимагый-политик мөнасәбәтләрен тамрыннан үзгәрткән, кешенең кешене эксплуатацияләвенә нигезләнгән барлык тәртипләрне җир шарының алтыдан бер өлешендә юк иткән Октябрь Социалистик Революциясе кешеләрнең аңында, дөньяга карашларында гаят зур үзгәреш ясады. Беренче һәм икенче бишьеллыкларның уңышлы үтәлүләре нәтиҗәсендә, Советлар Союзында эксплуататор сыйныфлар тәмам бетерелделәр, кешенең кешене эксплуатацияләвен һәм җәмгыятьнең эксплуататорларга һәм эксплуатацияләнүчеләргә бүленүен тудыра торган сәбәпләр тулысынча юк ителделәр. Безнең илебездә коммунизмның беренче фазасы — социализм нигездә тормышка ашырылды. Социализмның бу тарихи җиңүләре, бөек уңышлары культура революциясенең тагын да киң колач җәюе өчен, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерү өчен тирән нигез салдылар, гаят зур мөмкинлекләр тудырдылар. Социализмның чиксез зур уңышлары нәтиҗәсендә, фәннең, культураның чәчәк атуы нәтиҗәсендә, хезмәт ияләре арасында атеизм—динсезлек хәрәкәте көннән-көн үсә бара, дини идеология, дини хорафәтләр көннән-көн бетә баралар.

Ләкин бу әле безнең илебездә диннәр бетте, барлык хезмәт ияләре дә дини хорафәтләрдән азат ителделәр дигән сүз түгел. Һич шиксез, хәзер инде хезмәт ияләренең гаят зур күпчелеге дингә ышанмый, дини хорафәтләрдән азат ителгән, ләкин бер өлеше, дингә ышана әле, дини хорафәтләрдән әле булса азат ителгәне юк. Ураза тотулар, гает укулар, дини бәйрәмнәрне бәйрәм итүләр, пәри-җеннәргә, фәрештәләргә, оҗмахка, тамугка, такдиргә, төшкә ышану фактлары карткарчыклар арасында гына түгел, кызганычка каршы, кайбер яшьләр арасында да бар әле.

Диннең, дини хорафәтләрнең хезмәт ияләре өчен зарары гаят зур. Ураза, корбан—болар хезмәт ияләренә экономик яктан, сәламәтлек ягыннан гаят зур зарар китерәләр. Ураза аенда, һәр төрле дини бәйрәм көннәрендә кайбер урыннарда хезмәт дисциплинасын, авыл хуҗалыгы артеле уставын бозу кебек фактлар еш кына очрыйлар. Дәүләт өчен, хезмәт ияләре өчен бу нәрсәнең никадәр зарарлы икәнен сөйләп торасы юк.

Дингә каршы пропаганда эшен тагын да көчәйтү—ул, хәзерге вакытта иң әһәмиятле бурычларның берсе.

Хезмәт ияләре арасында, бигрәк тә дингә ышанучылар арасында, түземлелек, салкын канлылык белән һәр кемгә аңлашырлык итеп системалы рәвештә агитация-пропаганда алып бару, политик агарту эшен яхшы оештыру—дингә каршы пропаганда эшендәге төп метод менә шул.

Дингә каршы пропаганда һәм агитация эшенең төп эчтәлеге—партиябезнең XVIII нче съезды карарларындагы һәм иптәш Сталинның докладындагы бөек идеяләрне хезмәт ияләренә аңлатудан, диннең, дини гореф-гадәтләрнең зарарын ачып салудан, динчеләрнең мәкерләрен рәхимсез фаш итүдән гыйбарәт. Фәнни, иҗтимагый-политик темаларга лекцияләр, докладлар, беседалар уздырганда, барыннан да элек, аларның эчтәлегенә әһәмият бирергә кирәк, алар тирән эчтәлекле, идея-политик яктан югары дәрәҗәдә булырга тиешләр. Дингә каршы пропаганда эше социализм өчен көрәш бурычларына бәйләп алып барылырга, алардан аерылмаска тиеш.

Республикабызда дингә каршы пропаганда-агитация эшен яхшы гына итеп оештырган районнар юк түгел. Мисаль өчен Тәкәнеш, Дөбъяз, Әтнә, Азнакай районнарын алырга була. Бу районнарда дингә каршы пропаганда эшләре системалы рәвештә алып барыла, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында бу эш тагын да киңәйтелде. Дингә каршы пропаганда буенча Дөбъяз районында 25 кешедән, Тәкәнеш районында 18 кешедән, Азнакай районында 12 кешедән, Әтнә районында 20 кешедән торган лекторлар группасы эшләп киләләр. Лекторлар группасы тарафыннан хезмәт ияләре арасында системалы рәвештә фәнни, иҗтимагый-политик темаларда лекцияләр, докладлар үткәреләләр. Хезмәт ияләре бу лекцияләрне, докладларны зур кызыксыну белән тыңлыйлар.

Ләкин республикабызның күп кенә районнарында дингә каршы пропаганда эше гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар тора әле. Мондыйлар рәтенә Саба, Питрәч, Кызыл Йолдыз, Биектау, Мөслим, Бондюг районнары керә. Бу районнарда лекторлар группалары бөтенләй диярлек эшләмиләр, дингә каршы пропаганда буенча тәҗрибәләр уртаклашу киңәшмәләре, инструктив докладлар бик аз булалар, мәктәпләрдә дингә каршы тәрбия мәсьәләсенә тиешенчә игтибар бирелми. Пропаганда-агитация эшләренең көчле коралы булган матбугат—район газеталары дингә каршы пропаганда мәсьәләләрен онытканда бер яктырталар. Урнаштырылган материалларның да эчтәлеге канәгатьләнерлек булмый.

Дингә каршы пропаганда эшен үрнәк итеп кую өчен республикабызның барлык районнарында да бөтен мөмкинлекләр бар. Бу эштә социалистик интеллигенциябез—укытучылар, агрономнар, медицина работниклары көчләреннән тулысынча файдаланырга кирәк. Дингә каршы пропаганда эше—ул сугышчан алласызлар Союзының эше генә түгел, бу эштә комсомол, профсоюз һәм башка оешмалар якыннан катнашырга тиешләр.

Дингә каршы пропаганда—ул, марксизм—ленинизм пропагандасының аерылмас бер өлеше. ВКП(б) ның башлангыч оешмалары, райкомнары, дингә каршы пропаганда эшенә җитәкчелекне көчәйтергә тиешләр.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

16 нчы гыйнварда **Мурманский**, **Ухта** һәм **Реболы** юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре булды. Петрозаводск юнәлешендә пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте.

Карелия бугазында сирәк-сирәк артиллерия атышуы. Дошманның киң фронтта разведка алып барырга маташуы безнең разведка частьләре тарафыннан кире кайтарылды. Дошман зур югалтулар бирде.

Безнең авиация тимер юл узелларында һәм сугыш объектларында разведка хәрәкәтләре һәм урны-урны белән бомбага тоту хәрәкәтләре алып барды.

21 нче гыйнвар, кич 6 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта В. И. Лениннең тормышына һәм эшенә багышлап, Казан ШӘҺӘРЕ ПАРТИЯ, СОВЕТ, КОМСОМОЛ ҺӘМ ПРОФСОЮЗ АКТИВЫНЫҢ ТРАУР ҖЫЕЛЫШЫ БУЛА. Җыелышта „Иптәш Сталин җитәкчелегендә „Лениннән башка Ленин юлыннан 16 ел“ дигән темада доклад тыңланачак. (Докладчы иптәш Бычков).

Билетлар ВКП(б) ның һәм ВЛКСМ ның шәһәр райкомнары тарафыннан биреләләр.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

ССР СОЮЗЫ СОВНАРКОМЫНДА ҺӘМ ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

Колхозларда бөртекле культураларның сортлы чәчүлекләрен планлаштыру турында

ССР Союзы Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты сортлы чәчүлекләрне киңәйтү һәм орлыкларның сортлылык сыйфатларын яхшырту эшендә соңгы ике ел эчендә зур казанышлар булганлыкны күрсәтеп үтәләр.

Ләкин, бөртекле культураларның сортлы чәчүлекләрен планлаштыруның хәзерге тәртибе югары уңыш бирә торган иң яхшы селекция, шулай ук җирле сортларны иректә рәвештә сайлап алу эшендә колхозчыларның инициативасын чикли, шулай ук колхозларда бөртекле культуралар чәчүлекләренең билгеләнгән тәртибенә каршы килә.

Югары уңыш бирә торган сортларны дөрес сайлап алу юлы белән һәм бөртекле культураларның чәчүлекләрен сортлар буенча планлаштыру өчен колхозларның җаваплылыкларын көчәйтү юлы белән югары уңыш алуны тагын да арттыру эшендә колхозчыларның киң массасының инициативасын һәм кызыксынуын күтәрү теләген алга куеп, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирделәр:

1. Бөртекле культуралар сортларын чәчүне планлаштыруга карата чәчү мәйданнарын сортлар буенча колхозларга мәҗбүри рәвештә җиткерүне күздә тота торган тәртипне бетерергә.

2. Шушы зона өчен сортларны (төп сортлар һәм чәчелергә мөмкин булган сортлар, селекцияле, шулай ук җирле иң яхшы сортлар) кабул ителгәнчә районлаштыру чикләрендә колхозларның үзләренә сортларны үз карамаклары буенча сайлап алу хокукын бирергә.

3. Бөртекле культуралар чәчүлекләренә карата колхоз правлениеләре тарафыннан сортлар буенча эшләнә торган планнарны колхозчыларның гомуми җыелышлары тикшерүенә һәм раславына куярга колхоз правлениеләрен мәҗбүр итәргә.

4. Бөртекле культураларны сортлар буенча чәчүгә карата колхозчыларның гомуми җыелышлары тарафыннан кабул ителгән планнар тиешле тәртиптә район башкарма комитетлары тарафыннан расланырга тиеш, дип билгеләргә. Шуның белән бергә, район башкарма комитетлары колхозларның планнарына, бары тик колхоз тарафыннан китерелгән планга шушы зонада булмаска тиешле сортлар кертелгән хәлләрдә генә үзгәрешләр кертә алалар.

Колхозларда бөртекле культураларны сортлар буенча чәчү планнары район башкарма комитетлары тарафыннан расланган вакытта район орлык хуҗалыгы һәм шушы райондагы колхозларга хезмәт күрсәтүче сорт сынау участкысы агрономнарының катнашуларын мәҗбүри дип санарга.

5. Орлык участкылары өчен колхозларны югары сыйфатлы сортлы орлыклар белән тәэмин итү эшен киләчәктә дә, колхозларның сораулары һәм сортларны яңарту планы нигезендә, район орлык хуҗалыклары аркылы алып барырга.

6. ССР Союзы Наркомземының Сорт Идарәсен, республикаларның наркомземнарын һәм край (өлкә) җир бүлекләрен,—колхозлар тарафыннан бирелгән сораулар нигезендә орлык участкыларында сортларны яңарту өчен Госсортфонд челтәре аркылы колхозларга сортлы орлыклар бирергә мәҗбүр итәргә.

7. Колхозларда яңа перспектив сортларны чәчү эшләрен,—сортка карата производство ягыннан бәя бирүдә колхозчыларның киң рәвештә катнашуларын тәэмин итеп һәм производствога кертелә торган сортларга хуҗалык ягыннан дөрес бәя бирү өчен селекция станцияләренең һәм сорт сынау участкыларының җаваплылыгын көчәйтеп,—колхозларның ризалыгы белән үткәрергә.

8. Бөртекле культураларны сортлар буенча чәчүгә карата колхозлар тарафыннан кабул ителгән планнарны раслау эшен СССР ның көньяк районнарында 1940 нчы елның 15 нче февраленнән дә соңга калмыйча һәм калган районнарда—1940 нчы елның 25 нче февраленнән, ә киләсе елларда беренчесен—15 нче гыйнвардан һәм икенчесен—25 нче гыйнвардан соңга калмыйча тәмам итүне район башкарма комитетларын мәҗбүр итәргә.

9. СССР Госпланы янындагы Халык Хуҗалыгы Учеты Үзәк Идарәсен,—1940 нчы елда СССР ның көньяк районнарында 25 нче февральгә һәм СССР ның башка районнарында 5 нче мартка (ә киләсе елларны—беренчесен 25 нче гыйнварга һәм икенчесен—5 нче февральгә) бөртекле культуралар чәчүлекләренең планын һәм бу планның сортлар буенча фактта үтәлүен исәпкә алуны тәэмин итүне мәҗбүр итәргә.

10. СССР Наркомземына дәүләт селекция станцияләренең элита сортлы чәчүлекләренең планнарында 30 процент күләмендә һәм район орлык хуҗалыкларында районлаштырылган сортлы орлыкларның беренче һәм икенче репродукциясе буенча 25 процент күләмендә страховой фонд күздә тотуны такдим итәргә.

11. Икмәк пешерү ягыннан караганда кискен рәвештә төрле сыйфатта булган бодай сортлары колхозда булган хәлдә, ашлык тапшыру планын пешү сыйфатлары иң яхшы булган сортлар белән булмый.

12. Партия, совет һәм җир органнары, һәрбер колхозда бөртекле культураларны сортлар буенча чәчү планнарын төзүнең һәм колхозчыларның гомуми җыелышлары тарафыннан раслауның срогын билгеләп, сортлы чәчүлекләрне планлаштыру эшен оештыруда колхозларга һәр яклап ярдәм күрсәтергә тиешләр.

„И. Сталин“ бозваткычында митинг

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 16 гыйнвар. „И. Сталин“ һәм „Седов“ бозваткычындагы барлык кешеләрне, радио буенча **Сталин** һәм **Молотов** иптәшләрнең җылы котлау сүзләре алыну белән, гаят зур шатлык хисе чолгап алды.

Арктик флотның флагманында кичә митинг булды.

Иптәш Папанин болай диде:

— Иптәшләр, бүген безнең өчен иң бәхетле көн килде. Ватаннан ерак урында, ерактагы Гренландия диңгезендә, без данлыклы караб белән, Ленин—Сталин байрагын Арктиканың югары киңлекләре аркылы җиңүле рәвештә алып чыккан караб белән очраштык. Биредә, 80 нче параллельдә, без **Сталин** һәм **Молотов** иптәшләрнең радиограммасын алдык. Иптәш **Сталинның** безнең йөрәкләребезгә үтеп кергән җылы сүзләре бирегә, бозлар даласына һәм котып төне караңгылыгы эченә—безгә кадәр килеп җитте. Бу сүзләр прожектор нурларыдай Арктика караңгылыгын яктырттылар, алар безгә сөекле Ватаныбызның даны өчен алдагы көрәш юлын сыздылар.

Үзебезнең коллектив исеменнән партияне һәм хөкүмәтне ышандырырга рөхсәт итегез: Сталин заданиесенең икенче өлешендә без, социализм иле гражданнарына, совет патриотларына хас булганча, мактаулы рәвештә үтәрбез.

Совет халкының Ватаны хөрмәтенә, иптәш Сталин һәм иптәш Молотов хөрмәтенә куәтле „ура“ тавышлары яңгырый.

Аннан соң „Седов“ бозваткычының капитаны иптәш Бадигин чыкты.

Ул болай диде:

— Бүген безнең өчен бөек бәйрәм, без кечкенә генә эшебез өчен үзебезнең сөекле җитәкчеләребездән югары бәя алдык. **Сталин** һәм **Молотов** иптәшләрнең котлавы—бөек бәхет. Сөекле җитәкчеләребезгә без бөтен йөрәгебездән рәхмәт җибәрәбез. Без барыбыз да Ватанга кайтканнан соң да нык рәвештә эшләү, Ватаныбыз өчен, партиябез өчен, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин өчен барлык көчләрне бирү теләге белән янабыз.

Бозлар даласы өстендә тагын куәтле „ура“ яңгырый.

Митингта шулай ук Белоусов, Трофимов һәм башкалар сөйләделәр. Митингта катнашучылар көчле кул чабулар астында **Сталин** һәм **Молотов** иптәшләргә котлаулар җибәрделәр. (ТАСС).

Сталин районының 13 нче номерлы урта мәктәбе уку елының беренче яртысын гүзәл күрсәткечләр белән тәмам итте. РӘСЕМДӘ: рус теле һәм әдәбияты укытучысы иптәш С. И. Ионов. И. Галиев фотосы.

ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының чираттагы VIII нче пленумы турында

1940 нчы елның 13—16 нчы гыйнварында ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының чираттагы VIII нче пленумы булды.

Пленум „1939 нчы елны Татарстан партоешмасы буенча ВКП(б) га кабул итүнең йомгаклары турында“ ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Гафиәтуллин докладын тыңлады һәм тикшерде.

Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда: Хәкимҗанов (ВКП(б) ның Минзәлә райкомы), Тихонов (ВКП(б) ның Киров райкомы), Измайлова (ТАССР җинел промышленносты наркомы), Хәмидуллин (Ленин исемендәге завод), Шәмсеттинов (ВКП(б) ның Норлат райкомы), Палагин (ВКП(б) ның Молотов райкомы), Грехов (ВКП(б) ның Зеленодольский шәһәр комитеты), Шәрәфиеев (ТАССР Финанс Халык Комиссары), Бычков (ВКП(б) ның Казан шәһәр комитеты), Газизуллин (ВКП(б) ның Беренче Май райкомы), Петров (тимер юлның Әгерҗе узелы), Жуков (ВКП(б) Өлкә Комитеты), Зайцев (ВКП(б) ның Сталин райкомы), Акчурин (ВКП(б) ның Шөгер райкомы), Мингалиев (ВКП(б) ның Әгерҗе райкомы), Тараканов (ВКП(б) ның Красный Бор райкомы), Җиһаншин (Красный Восток совхозы), Баһаветтинов (ВКП(б) ның Вондюг райкомы), Щербинин (ВКП(б) ның Чаллы райкомы), Мандур (Казан тимер юлы политбүлеге) иптәшләр катнаштылар.

Аннары пленум „1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлек турында“ ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш Тынчеров докладын тыңлады һәм тикшерде.

Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда Сәмигуллин (ВКП(б) ның Ворошилов райкомы), Вахрушев (ВКП(б) ның Мамадыш райкомы), Соколов (ТАССР Наркомземы), Максудов (Киров исемендәге совхоз), Хәйбуллин (ВКП(б) Өлкә Комитеты), Школдов (ВКП(б) ның Норлат райкомы), Саланов (ВКП(б) Өлкә Комитеты), Иванов (ВКП(б) ның Заинский райкомы), Зыбин (Совхозтрест), Ибраһимов („Татарстан“ совхозы), Никишкин (Хәзерләүләр халык комиссариатының Татарстан буенча уполномоченные), Кузнецов (ВКП(б) ның Биектау райкомы), Черзор (ТАССР Наркомземы), Сүслиганова („КИМ“ совхозы), Рундаев (Совет Контроле Комиссиясенең Татарстан АССР буенча уполномоченные), Коростин (главтракторсдеталь), Садовников (ТАССР Совнаркомы), Быстров (ТАССР госпланы), Перов (ТАССР прокуроры), Матвеев (ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре) иптәшләр катнаштылар.

Бу мәсьәләләр буенча пленум тиешле карарлар кабул итте.

Пленум И. К. Радыгин һәм П. С. Огнев иптәшләрне Өлкә Комитеты пленумы членлыгыннан азат итте. Иптәш И. Н. Зайцевны пленум составыннан чыгарды.

Пленумда, ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. М. Алемасов йомгаклау речь белән чыкты.

КОМСОМОЛНЫҢ ӨЛКӘ КҮЛӘМЕНДӘГЕ АКТИВ ҖЫЕЛЫШЫ

Комсомолның өлкә күләмендәге актив җыелышының 17 нче гыйнвардагы утырышында, ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы йомгаклары турындагы доклад буенча фикер алышулар булды.

Алексеевский районының мәгариф бүлеге мөдире иптәш Забильев комсомол Үзәк Комитетының X нчы пленумы карарлары мәктәпләр һәм бөтен совет җәмагатчелеге тарафыннан зур күтәренкелек белән каршылануы турында сөйләде. Ул районда яхшы эшләүче укытучыларның тәҗрибәләрен күрсәтеп үтте. Шулай да әле күп кенә мәктәпләрдә уку, тәрбия эшләре ныклы юлга куелмаган. Райондагы мәктәпләрдә укудан гомуми өлгереш 75 процентган артмый, ә кайбер мәктәпләрдә 50 процент кына. Урта мәктәпләрнең югары классларында өлгереш тагы да түбән. Бу хәл югары класс укытучыларының еш алмашынуы һәм укуларның сыйфаты өчен ныклы көрәш оештырылмау нәтиҗәсендә килеп чыккан. Мәсәлән, Балахчинский мәктәбендә 1932 нче елдан башлап 45 укытучы алмашынган.

Фикер алышуларда катнашучы башка иптәшләр дә мәктәпләрдә укуларның сыйфаты һәм укучыларның дисциплинасы өчен көрәш канәгатьләнерлек булмауны күрсәткән шундый күп кенә фактларны китерделәр.

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре иптәш Ханова мәктәпләрдә комсомол һәм пионер оешмалары эшләрен оештыру чараларына тукталды һәм мәктәпләр эшендәге кимчелекләрне күрсәтте.

Татарстан мәгариф халык комиссары иптәш Контюков Совет иленең яшь буынын тәрбияләү мәсьәләләренә тукталып, мәктәпләрнең бүгенге эш торышыннан күп кенә мисаллар китерде. Мәктәпләрдә, бигрәк тә рус телен укыту эшендә орфография режимын бозу фактлары бар. Укучылар арасында коммунистик мораль өчен көрәш канәгатьләнерлек түгел әле.

Актив җыелышында ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш Динмөхәметов речь белән чыкты. Ул, ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан комсомол оешмалары һәм мәктәпләр алдына куелган җаваплы бурычларны һәм совет балаларын тәрбияләү эшендәге җидди кимчелекләрне күрсәтте.

Актив җыелышы доклад буенча конкрет карар кабул итте һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга котлау хаты җибәрде.

ВКП(б) НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ VIII НЧЕ ПЛЕНУМЫ

1939 НЧЫ ЕЛНЫ ПАРТИЯНЕҢ ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНДА ВКП(б) ГА КАБУЛ ИТҮНЕҢ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карары

„1939 нчы елны партиянең Татарстан оешмасында ВКП(б) га кабул итүнең йомгаклары турында" иптәш Гафиятуллин докладын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы, узган чор эчендә партиянең Татарстан оешмасы үзенең сафларын оештыру ягыннан тагын да күбрәк ныгытты, хезмәт ияләренең киң массасы белән үзенең элемтәсен көчәйтте, аларның политик һәм производство активлыгын оештырды һәм аңа җитәкчелек итте, болар партия оешмасының авторитетын һәм хезмәт ияләре тарафыннан аңа карата ышанычны тагын да югары күтәрделәр һәм аның сафлары эшчеләрнең,колхозчыларның һәм интеллигенциянең иң яхшы өлеше исәбенә 57,4 процентка үсте, дип күрсәтеп үтә.

Партия оешмасы сафларының үсүе, бер үк вакытта, ВКП(б) сафларына яңа кабул ителүчеләрнең идея ягыннан кораллануларының һәм практик эштә активлыкларының үсүе белән бергә барды. 1939 нчы елның икенче яртысы эчендә генә дә район күләмендә һәм түбәнге җитәкче эшкә күтәрелгән коммунистларның 30 проценты ВКП(б) сафларына 1939 нчы елны кабул ителүчеләр.

Шуның белән бергә, ВКП(б) Өлкә Комитеты Пленумы, Аксубай, Югары Ослан, Кызыл Йолдыз, Саба , Чистай, Дөбъяз һәм Теләче районнарында башлангыч партоешмаларның практикасын бөтенләй дөрес түгел дип хисаплый, алар бу районнарның ВКП(б) райкомнары 32 кешене партиягә алмауга да карамастан, сан артыннан куып индивидуаль сайлап алу принципларын боздылар, ВКП(б) га кабул итү турында гариза биргән һәр кемне партия сафларына алдылар.

Партиягә кабул итү эшенә җидди булмаган, игтибарсыз якын килү фактлары Киров, Азнакай, Сталин, Молотов районнарында да һәм кайбер башка райкомнарда да һәм ВКП(б) ның Зеленодольский шәһәр комитетында да булды. Шуның нәтиҗәсендә, ВКП(б) ның кайбер райкомнары, аерым хәлләрдә, тикшерелмәгән, лаеклы булмаган кешеләрне партиягә кабул иттеләр, бу райкомнар кабул итү белән үк мондый кешеләрне партиядән чыгарырга яки аларны ныклы партия җаваплылыгына тартырга мәҗбүр булдылар.

ВКП(б) ның күп кенә райкомнары кабул ителүчеләрнең составын өйрәнмиләр, партия оешмаларының үсүен регулярлаштыру, шәһәрнең һәм авылның төп профессия работникларын партиягә тарту мәсьәләләренә игтибар бирмиләр. Шуның нәтиҗәсендә, 1939 нчы елны авыл партоешмаларында ВКП(б) сафларына алынучылар арасында тракторчылар бары 3,5 процент, комбайнчылар 1,8 процент, агрономнар 2,1 процент, ә промышленность предприятиеләре янындагы партоешмаларда партиягә кабул ителүчеләр арасында төп профессия кешеләр 6 нчы тегү фабрикасында—13,8 процент, җитен комбинатында—18,3 процент, Серго Орджоникидзе исемендәге заводта 21,6 процент тәшкил итә.

Шуның белән бергә, Пленум, ВКП(б) сафларына кабул ителүчеләр арасында хатын-кызлар процентының бик түбән булуын (17,3 процент) күрсәтеп үтә. Хатын-кызлар хезмәте шактый өстен урын алып тора торган предприятиеләр янындагы партоешмаларга карата бу хәл аеруча гафу ителмәслек (җитен комбинаты, 6 нчы тегү фабрикасы, Мехкомбинат, „Спартак" комбинаты һәм башкалар).

Партиянең Татарстан оешмасы составында кандидатлык стажлары үткән 3.674 кандидат булуга, ә Азнакай, Аксубай, Кузнечиха, Кызыл Йолдыз һәм Питрәч райпартоешмаларында кандидатлар саны ВКП(б) членнары саныннан күп булуга карамастан, ВКП(б) ның шушы һәм күп кенә башка райкомнары кандидатларны ВКП(б) членлыгына керүгә хәзерләү буенча тиешле эш алып бармыйлар, кандидатларның практик эш өстендә үсүләренә җитәкчелек итмиләр, аларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү өчен кирәкле шартларны тудырмыйлар, аерым хәлләрдә кандидатларны үз язмышларына куялар. Ул гына да түгел, ВКП(б) сафларына кабул ителгән һәм ВКП(б) га яңадан кайтарылган 688 кешенең шушы вакытка кадәр партия документлары юк.

ВКП(б) сафларына кабул итү эшендәге һәм яңа кабул ителүчеләр белән эшләүдәге шушы барлык һәм күп кенә башка кимчелекләр, күп кенә райком секретарьларының партиябез тормышында гаять әһәмиятле булган бу мәсьәлә белән үзләренең шөгыльләнмәүләренең яки бу эшне ВКП(б) райкомнарының оештыру - инструкторлык бүлекләренә ышанып тапшырып, очраклы рәвештә генә шөгыльләнүләренең, аларның эшенә кирәкле контрольне һәм җитәкчелекне тормышка ашырмауларының турыдан-туры нәтиҗәсе.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карар бирә:

ВКП(б) сафларына кабул итү эшендә һәм партиягә яңа кабул ителүчеләрне тәрбияләү эшендә югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү теләге белән, Пленум ВКП(б) ның шәһәр комитетларын һәм райкомнарын мәҗбүр итә:

1. ВКП(б) уставын нык кулланырга, ВКП(б) сафларына кабул итү эшендә тулай, өстән генә якын килүгә юл куймаска, эшчеләрнең, колхозчыларның, интеллигенциянең иң яхшы өлешен партиягә сайлап алуны йомшартмаска, шул ук вакытта промышленностьның, транспортның һәм авыл хуҗалыгының төп профессиясендә эшләүче политик һәм эшлеклелек ягыннан сыналган алдынгы кешеләрен партиягә кабул итүгә аеруча әһәмият бирергә.

2. Партиягә кабул итү вактында ВКП(б) уставын бозуның бер генә фактын да (3 рекомендация бирү турында устав таләпләрен сакламау, рекомендация бирүченең рекомендация алучыны бер елдан ким белүе һәм башкалар) игтибарсыз калдырмаска һәм һәрбер факттан кирәкле нәтиҗә ясарга, бу фактларны ВКП(б) шәһәр комитетларының һәм район комитетларының бюро утырышларында, тиешле булган башлангыч партоешма секретарьларының катнашы белән тикшерергә, шулай итеп, ВКП(б) га кабул итүдә ялгышларны кабатламау өчен башлангыч партоешмаларга кисәтеп куярга.

3. Партиягә кабул итүдән баш тарту турындагы барлык хәлләрдә, партиянең шәһәр комитетларының һәм район комитетларының партиягә кабул итү турындагы карарны үзгәртүләренең мотивларын шундый һәрбер факт буенча, башлангыч партоешмаларның гомуми җыелышларында аңлатырга, ВКП(б) га кабул итү турындагы мәсьәләләрне хәл иткәндә башлангыч партоешмаларны шушы үрнәкләрдә дөрес якын килә белергә өйрәтергә.

4. Хатын-кызлар арасында, бигрәк тә авыл җирләрендә, эшләүгә игтибарны көчәйтергә, аларны җәмагать оешмаларында эшләүгә актив тартырга, аларга практик эштә дә, шулай ук аларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрүдә дә аларның үсүенә ярдәм итәргә һәм аларның иң яхшыларын ВКП(б) сафларына сайлап алырга.

5. Партиянең барлык кандидатларын көндәлек рәвештә, җентекләп һәм индивидуаль рәвештә өйрәнүне тәэмин итәргә, аларны практик эштә тикшерергә, аларның идея-политик яктан үсүләренә барлык чаралар белән ярдәм итәргә. Кандидатлык сроклары чыгу белән үк партия оешмасы ВКП(б) га член итеп кабул итү буенча партиянең һәрбер кандидаты турындагы мәсьәләне аерым рәвештә нык хәл итә алырлык булырга тиеш.

Пленум, партиянең барлык оешмаларын ВКП(б) членлыгына кандидатлар белән эшләүне җидди рәвештә яхшыртырга кирәклеккә, бигрәк тә аларның, кандидатлык стажлары чыкканнары белән эшләүне көчәйтергә кирәклеккә игтибарларын аеруча юнәлдерә.

6. ВКП(б) сафларына кабул ителгәннәрнең һәм яңадан кайтарылганнарның барсына да 1940 нчы елның 1 нче февраленә кадәр партдокументлар бирүне оформить итәргә һәм киләчәктә, партиягә алынучыларга һәм ВКП(б) га яңадан кайтарылучыларга, партиягә кабул итү яки ВКП(б) га яңадан кайтару турында карар кабул ителү көненнән 10 көннән дә соңга калмыйча партдокумент бирелерлек итеп тәртип урнаштырырга.

Шуның белән бергә, Пленум, барлык партоешмаларның игтибарын барлык коммунистларның да үзләренең партдокументларын саклау өчен җаваплылыкларын арттыру кирәклеккә аеруча юнәлдерә.

7. ВКП(б) га яңа членнар кабул итүнең барышы турында һәм партия кандидатлары белән эшләү турында аерым башлангыч партоешмаларның отчетларын ВКП(б) ның шәһәр комитетлары һәм район комитетлары бюросында системалы рәвештә тыңларга, бу эштә башлангыч партоешмаларның эшен җентекләп тикшерергә. Башлангыч партоешмаларда ачылган һәрбер кимчелекне партия оешмасының гомуми җыелышында да, шулай ук партиянең башлангыч оешмалары секретарьларының киңәшмәсендә дә тикшерергә.

8. 1940 нчы елның 10 нчы февраленә кадәр ВКП(б) шәһәр комитетларының һәм район комитетларының пленумнарын үткәрергә, аларда шәһәр һәм район партоешмаларында ВКП(б) га кабул итүнең йомгакларын һәм яңа кабул ителүчеләр арасында эшләүнең торышын тикшерергә. Киләчәктә бөтен шәһәр һәм район партоешмалары буенча ВКП(б) га кабул итү һәм яңа кабул ителгәннәрне тәрбияләү мәсьәләләрен ВКП(б)ның шәһәр комитетлары һәм район комитетлары пленумнары тикшерүенә регуляр рәвештә куярга.

* * *

ВКП(б) Өлкә Комитеты Пленумы ТАССР дагы һәрбер партия оешмасыннан, партиягә яңа членнар кабул иткәндә, ВКП(б) Уставын, индивидуаль сайлап алуның большевистик принципларын нык саклауны тәэмин итүләрен, дошманчит элементларның ВКП(б) сафларына үтеп керүгә булган һәр төрле омтылышларына кискен отпор бирүләрен, партия сафларына политик һәм эшлеклелек ягыннан тикшерелгән иң яхшы кешеләрне, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән эшчеләрне, колхозчыларны һәм интеллигенцияне сайлап алуларын таләп итә.

1940 НЧЫ ЕЛГЫ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК ТУРЫНДА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карары

1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерлек турында Татарстан АССР Совнаркомы председателе иптәш Тынчеровның докладын тыңлап тикшергәннән соң, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы үткән 1939 нчы елның Татарстан АССР да авыл хуҗалыгы өлкәсендә яңа уңышлар белән билгеләнгәнлеген күрсәтеп үтә. Партиянең Татарстан оешмасы, ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын һәм шуннан соң „Колхозларның җәмагат җирләрен әрәм-шәрәм итүдән саклау чаралары турында" һәм „Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында" СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан чыгарылган карарларны үтәп, колхоз милекчелеген ныгытуга, колхозларда җирдән файдалануда большевистик тәртип урнаштыруга иреште. Терлекчелек фермаларының саны артты, авыл хуҗалыгының машина техникасы белән кораллануы үсте, тракторчыларның, бригадирларның, комбайнчыларның, колхоз председательләренең меңнәрчә яңа кадрлары үсте, стахановчыларның саны артты.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе колхоз строеның данлыклы җиңүләренең йомгакларын күрсәтте. Бу күргәзмәдә Татарстаннан 457 колхоз катнашты, колхоз һәм совхоз производствосы алдынгыларыннан һәм оештыручыларыннан 2.600 кеше катнашты. Бу уңышлар барсы да—колхозчы крестьяннар турында Сталинчыл көндәлек кайгыртучанлыкның нәтиҗәсе.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, шушы уңышлар белән бер рәттән, авыл хуҗалыгының аерым эшләрен үтәүдә җидди кимчелекләргә дә юл куелганлыкны күрсәтә. Республикада тулаем алганда трактор эшләренең еллык планы 77,3 процентка гына үтәлгән, иген уңышы буенча дәүләт планы үтәлмәгән. Татарстанда техник культуралар эшенең таркау булуы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының ныклы кисәтүе булуга карамастан, бу хәл әле һаман да төзәтелмәгән һәм асылда таркау хәлдә кала.

1939 нчы елны авыл хуҗалыгы эшләренең аерым төрләрен үтәмәүнең һәм язгы чәчүгә кәнагатьләнерлек хәзерләнмәүнең 1940 нчы елны югары һәм ныклы иген уңышы өчен көрәшне уңышлы җәелдерүгә тоткарлык ясаганлыгын пленум аеруча күрсәтеп үтә. Шуның нәтиҗәсендә орлыклар салу, аларны чистарту һәм сыйфатын тикшерү чиктән тыш акырын бара. Бу эш Әлки, Биләр, Кызыл Армия, Яңа Чишмә һәм күп кенә башка районнарда бигрәк тә начар тора. Кышкы агрономия чаралары планы, тирес чыгару, кар тоту, көл җыю, минераль ашламалар чыгару һ б. гаять начар үтәлә. Әлмәт, Столбище, Алексеевский, Акташ районнары бу эшне асылда җәелдермәгәннәр дә. Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау канәгатьләнмәслек бара. Шушы елның 5 нче гыйнварына республикада тулаем алганда тракторларга ремонт ясауның еллык планы 30,8 процентка гына үтәлгән. МТС һәм совхоз директорлары тракторларга ремонт ясау эшенә начар җитәкчелек итәләр, тунга сөрү планының бары 64 процентка гына үтәлгәнлеген һәм язгы чәчү чорында 843 мең гектар җирне сөрергә туры киләчәген искә алмыйлар. Нөркәй, Тымытык һәм Теләче МТС лары тракторларга һәм тагылма машиналарга ремонт ясауны 1 нче гыйнварга срогыннан алда тулысынча төгәлләгән булсалар, Зөя һәм Кузайкино МТС ларында бер генә тракторга да ремонт ясалмаган, Зирекле МТС ында ремонт планы бары 14,6 процентка, Буа МТС ында 16,7 процентка һәм Мөрәле МТС ында 6,1 процентка гына үтәлгән. Механизаторлар кадрлары һәм массовый колхоз кадрлары хәзерләү күпчелек районнарда ачыктан-ачык канәгатьләнмәслек бара. Бу, ТАССР Наркомземның, район башкарма комитетларының һәм ВКП(б) райкомнарының машина—трактор станцияләре эшенә җитәкчелек итүгә игтибарларын йомшартулары белән, кадрларны дөрес сайлап алуда һәм урнаштыруда, аларның квалификацияләрен күтәрүдә аларга һәр вакыт ярдәм итмәүләре белән аңлатыла. Күп кенә районнарда (Кайбыч, Югары Ослан, Кама Тамагы һәм күп кенә башка районнарда) МТС ларда, колхозларда һәм совхозларда массовый-политик эш түбән дәрәҗәдә калуында дәвам итә. Бу районнарның ВКП(б) райкомнары һәм район башкарма комитетлары бөртекле культуралар буенча һәр гектардан йөз пот уңыш алу өчен Бөтенсоюз социалистик ярышына колхозчылар массасын, совхозларның һәм МТС ларның эшчеләрен йомшак тарталар.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карар бирә:

1. ТАССР Наркомземын, Татсовхозтрестны, ВКП(б) райкомнарын, район башкарма комитетларын, район җир бүлекләрен, МТС ларның, МТМ нарның һәм совхозларның директорларын мәҗбүр итәргә:

а) МТС ларда һәм совхозларда тракторларга һәм тагылма инвентарьга ремонт ясауны 1940 нчы елның 25 нче февраленә һәм колхозларда гади машиналарга (чәчү машиналарына, сабаннарга, тырмаларга һ. б.) ремонт ясауны—20 нче мартка тәмам итәргә. Барлык машиналарның ремонт сыйфатына көндәлек контроль булдырырга, ремонт ясалган тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын тикшерү һәм кабул итү вактында ачылган кимчелекләрне тизлек белән төзәтергә.

б) Шушы елның 25 нче мартына барлык трактор бригадаларын тракторчылар, прицепщиклар белән һәм иң яхшы колхозчылардан һәм совхоз эшчеләреннән хезмәт күрсәтүче персонал белән кирәкле санда комплектлаштырырга, һәрбер трактор бригадасын кирәкле инструментлар һәм көйләү инвентаре комплекты белән тәэмин итәргә.

в) Эшләп чыгару нормалары, ягулыкны тоту, хезмәткә түләү һәм бүләкләү тәртибе, шулай ук тракторларны һәм машиналарны техник яктан карау планы төзергә һәм аларны тракторчылар белән берлектә тикшерергә.

г) 15 нче мартка газогенераторлы тракторлар өчен ягулык хәзерләүне, киптерүне һәм тиешенчә саклауны тәэмин итәргә, МТС ларның һәм совхозларның бөтен трактор парки өчен ягулык һәм майлау материалы ташуны тулысынча тәмам итәргә.

д) Шушы елның 25 нче мартыннан да соңга калмыйча тракторчылар өчен вагоннар хәзерләүне тәмам итәргә һәм аларны культура-көнкүреш нәрсәләре белән (көтепханәләр, аптечкалар, шашкалар, шахматлар, музыка инструментлары, урын-җир нәрсәләре һ. б.) җиһазларга, җәмагат туклануын вактында оештыруга аеруча игтибар бирергә.

е) Механизаторлар кадрлары курсларын һәм мәктәпләрен комплектлауны 25 нче гыйнварга кадәр тулысынча тәмам итәргә, бу курсларга һәм мәктәпләргә хатын-кызларны иң күп санда тартырга, укыту-тәрбия эшенең куелышына һәм укучыларга нормаль культура-көнкүреш шартлары булдыруга җидди игтибар бирергә.

2. МТС ларны, МТМ нарны һәм совхозларны запас частьләр белән, тракторларга һәм машиналарга көзге-кышкы ремонт өчен кирәкле материаллар белән вактында һәм дөрес тәэмин итү эшендә Главтрактородетальнең һәм Сельхозснабның эше һич тә канәгатьләнерлек булмавын билгеләп,—пленум, Корыстин һәм Саттаров иптәшләрне трактор детальләрен һәм авыл хуҗалыгы машиналарына запас частьләрне үз вактында китерү һәм дөрес бүлеп бирү өчен бөтен чараларны күрергә мәҗбүр итә.

3. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы чәчүгә атларны һәм транспортны иң яхшы итеп хәзерләү кирәклегенә игтибарны аеруча юнәлтә. Шушы теләк белән совхозларның директорларына һәм колхозларның председательләренә такдим итәргә:

а) Атны үрнәк булырлык итеп тәрбияләүне, анардан дөрес файдалануны хәзердән үк тәэмин итәргә һәм атларны иясезләндерүнең һәм начар тәрбияләүнең барлык күренешләренә каршы иң кискен көрәш алып барырга.

б) Чәчү башланганга кадәр аз көчле атларны эшкә тулысынча яраклы итү өчен аларны хәзердән үк ялга куярга, ә язгы чәчү башлануга 15—20 көн кала барлык эш атларын ялга һәм аерым тукландыруга куярга.

в) Төзәтү һәм яңаларны ясау юлы белән транспорт һәм сбруйлар хәзерләргә, 25 нче мартка кадәр һәрбер колхозда һәм совхозда барлык эш атларына җитәрлек санда сбруйлар һәм кирәкле санда арбалар булдыруга ирешергә.

г) Шушы елның 1 нче февраленә кадәр эш атлары өчен аларның чәчү алдыннан булачак яллары вактына һәм бөтен язгы чәчүне үткәрү өчен кирәкле санда һәрбер колхозда һәм совхозда тупас һәм концентрат азык бүлеп куярга һәм аны әрәм-шәрәм итүгә юл куймаска.

4. 1940 нчы елны бөртекле, кузаклы һәм техник культуралар буенча язгы чәчүне югары сыйфатлы кондицион сортлы орлыклар белән тәэмин итү өчен, ТАССР Наркомземын, Татсовхозтрестны, ВКП(б) райкомнарын, район башкарма комитетларын, район җир бүлекләрен, МТС һәм совхоз директорларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) Орлыклык һәм страховой фондлары салуны, рядовой орлыкларны колхозлар арасында сортлыларга алмаштыруны, шулай ук орлыкларны чистартуны һәм аларның сыйфатын тикшерүне, аларны чәчү кондициясенә кадәр җиткерүне 1940 нчы елның 20 нче февраленә тәмам итәргә. Шул ук срокка орлыклык участкылары һәм райсемхозлар өчен Госсортфондтан яхшыртылган орлыклар алуны тәмам итәргә. Мартның икенче яртысында орлыкларның тишелүчәнлекләрен икенче кат тикшерү үткәрергә, аларны тулысынча саклап калу өчен барлык чараларны күрергә. Чәчүлек материалларын бозуга яки урлауга юл куйган кешеләрне иң каты җавапка тартырга.

б) Техник культураларына бәя биреп җиткермәүне бетерергә. Җитенне, киндерне беренче кат эшкәртүне тәмам итүне һәм продукцияне дәүләткә тапшыруны, шулай ук орлык салуны тәэмин итәргә, техник культуралар чәчү өчен иң яхшы участкылар билгеләүгә һәм минераль ашламалардан тулысынча файдалануга аеруча игтибар бирергә.

в) Бәрәңге һәм яшелчә культуралары орлыкларының күләмен һәм аларны кыш көне саклауны тикшерүне оештырырга, аларны тулысынча саклап калуны тәэмин итәргә.

г) Хезмәтне звенолап оештыру нигезендә, кышкы агрономия чаралары планын: кар тоту, тирес чыгару һәм саклау, көл, фекаль һәм кош тизәге җыю, минераль ашламалар чыгару һ. б. планын сан һәм сыйфат ягыннан һич сүзсез үтәүгә һәм арттырып үтәүгә ирешергә.

д) Колхозларда, совхозларда һәм бригадаларда агротехника укулары һәм стахановчылык мәктәпләре оештырырга, авыл хуҗалыгы алдынгыларының — Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашучыларның тәҗрибәләрен һәм югары иген уңышы буенча Ефремовчылар звеноларының тәҗрибәләрен киң рәвештә өйрәнергә һәм файдаланырга.

5. „Колхозларда бөртекле культуралар чәчүлекләрен планлаштыру тәртибе турында" СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын һич сүзсез үтәү теләге белән, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы райкомнарны, район башкарма комитетларын авыл хуҗалыгы белгечләре һәм район активы көчләре белән чәчүлекләрне планлаштыруда колхозларга барлык чаралар белән ярдәм итәргә, бу эшне СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 28 нче декабрь карарына нык туры китереп үткәрергә мәҗбүр итә.

6. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы ТАССР Наркомземын, ВКП(б) райкомнарын, башкарма комитетларын, район җир бүлекләре мөдирләрен, МТС, совхоз директорларын, колхоз председательләрен, — парниклар-теплицалар хуҗалыгы, бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләре чәчү планын үтәргә, теплицаларда чәчүнең февраль аенда үткәрелүенә аеруча игтибар бирергә мәҗбүр итә. Бер үк вакытта пленум якындагы еллар эчендә һәрбер совхозда, колхозда һәм колхозчы хуҗалыгында үзенең җиләк-җимеш бакчасы булсын өчен бакчачылык эшен җәелдерергә кирәк дип саный.

7. Терлекчелек өчен ныклы азык базасы булдыру һәм чәчү әйләнешен дөрес алып бару теләге белән район җир бүлекләренә, колхозларга һәм совхозларга азык культуралары—үләннәр һәм азыктамырлар хәзерләүне һәм аларны саклауны үзләренең ныклы контрольләренә алырга, бу культураларны кысрыклап чыгарырга маташучыларга каршы кискен рәвештә көрәшергә такдим итәргә.

8. Колхозчыларның, ялгыз хуҗалыкчыларның һәм колхоз члены булмаган башка кешеләрнең каралты тирәсе участкыларыннан кисеп алынган һәм колхозларның 1940 нчы елга җәмагать чәчүлекләре планына кертелгән барлык сөрелә торган җирләрдән тулысынча файдаланырга

9. Барлык колхозларга үзләренең 1939 нчы елгы еллык отчетларын вактында төзүне, аларны колхозчыларның гомуми җыелышларында тикшерүне һәм раслауны тәэмин итәргә һәм авыл хуҗалыгы артеле уставына тулысынча туры китереп колхозларда доход бүлүне тәмам итәргә.

10. МТС директорларына һәм колхоз председательләренә,—1940 нчы елның 20 нче февраленә кадәр колхозларда МТС белән колхозлар арасында 1939 нчы елга төзелгән договорларның үтәлеше турында отчетлар үткәрергә һәм 10 нчы мартка кадәр 1940 нчы елга договорлар төзергә такдим итәргә.

11. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы ВКП(б) райкомнарын һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетын,—колхозлардагы башлангыч комсомол оешмаларына, бигрәк тә партия оешмалары булмаган урыннарда җитәкчелек эшен яхшыртырга, колхоз алдында тора торган хуҗалык-политик бурычларны хәл итүдә аларга барлык чаралар белән ярдәм итәргә һәм аларның инициативаларын барлык чаралар белән якларга, язгы чәчүгә уңышлы хәзерләнүгә аларның игтибарын тупларга мәҗбүр итә.

12. Татарстан АССР авыл хуҗалыгының уңышларын 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә кинрәк күрсәтү максаты белән,—пленум район башкарма комитетларын, җир органнарын һәм ВКП(б) райкомнарын Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә үз эшләренең күрсәткечләре буенча катнаша алырлык иң яхшы МТС ларны, колхозларны һәм совхозларны, шулай ук авыл хуҗалыгы алдынгыларын табу һәм рәсмиләштерү эшен оештырырга мәҗбүр итә.

* * *

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы партиянең, комсомол, совет һәм профсоюзның барлык оешмаларын — массовый политик эшне, социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен кинрәк җәелдерергә, массаның иҗад активлыгына җитәкчелек итәргә, алдынгыларның—Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашачак кешеләрнең сафларын армый-талмый арттырырга, колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда хезмәт дисциплинасын тагын да ныгыту өчен, иген уңышын күтәрү өчен, колхозларны тагын да үстерү һәм оешу - хуҗалык ягыннан ныгыту өчен көрәшергә чакыра.

МОРОЗОВ СТАЧКАСЫ

1885 нче ел 19 (7) нче гыйнвар—1940 нчы ел 19 нчы гыйнвар

80 нче еллар Россиянең социаль яктан яңадан үзгәрүенең тирән эчке процессы белән характерләналар. Аренага яңа сыйныфлар, бер яктан—буржуазия, икенче яктан—эшчеләр сыйныфы килеп басалар.

Крепостниклар—алпавытлар хөкүмәте, үзе шулар ярдәме белән идарә итә торган штык һәм камчы системасын ныгытып, яңа туып килә торган буржуазиянең бу кышлыгы белән эзлекле рәвештә реакцион политика үткәрде. Салтыков-Щедрин „Идеаллар, азатлык, җанның ашкынулары—барсы да онтылды, коллыкка корбан ителде“ диде.

Бу елларда Россиянең капиталистик хуҗалыгы җидди кыенлыклар кичерде. Москва газетасы болай дип язды: „Промышленностыбыз тарихында шул кадәр озакка сузылган торгынлыкның үрнәге әлегәчә булганы юк иде әле. Бу—промыслоны тиз җимерә һәм тиз читләтеп үтеп китә торган үткен кризис түгел; бу—товарга булган соравның ниндидер җансыз, күңелсез хәлдә булуы, ул кризисның очы-кырые күренми, ул булган вакытта һәр кем, үзен иртәге көнне нәрсә көткәнне белмиче, көннән-көн җөди“ [1]). Фабрикантлар эшчеләр сыйныфына көчәйтелгән һөҗүм ясау белән үз эшләрен төзәтергә карар бирделәр: алар эшчеләр санын кыскарта, хезмәт хакын киметә башладылар. Кайбер фабрикаларда хезмәт хакы 30—40 процент кимеде. Эш көне озайтылды: текстиль промышленностында ул 14—15 сәгатькә җитте. Штрафлар әлегәчә ишетелмәгән күләмнәргә җиттеләр.

Мондый хәлнең эшчеләрнең нәфрәтен һәм отпор бирүен тудырмавы мөмкин түгел иде. Стачкалар ярдәме белән эшчеләр үз интересларын яклый башлыйлар. Стачка хәрәкәте үсә, 1881 нче елдан 1886 нчы елга кадәр биш ел вакыт эчендә 48 дән артык зур стачкалар булганлыгы исәпләнә. Аларда 80 мең эшче катнашты. „Дело“ журналы: „Бездә озак вакыт тынып торган эшчеләр мәсьәләсе гүя җирдән үсеп чыккан һәм үз алдыбызга килеп баскан кебек булды“—дип язган.

Морозовның Орехово - Зуеводагы Никольский мануфактурасында 1885 нче елны башланып киткән зур стачка ул замандагы оешканлыкның гадәттән тыш үрнәге булып тора.

Морозовның Никольский мануфактурасы үзенең тәртипләре белән бөтен округта дан алды. Анда эшчеләрне эксплоатацияләү аеруча ерткычларча барды. 1882 нче елдан 1884 нче елга кадәр фабрикада хезмәт хакы биш тапкыр кимеде, шуның белән бергә 1884 нче елны расценклар кинәт 25 процентка түбәнәйтелделәр. Эшчеләрне ачыктан-ачык талау барды. Эшчеләрнең эшләп алган һәрбер сумыннан штрафлар тесендә фабрикант файдасына 30 тиеннән 50 тиенгә кадәр алып калалар иде. Морозов бар нәрсә өчен дә штраф сала: тәмәке тарткан өчен 3,4 хәтта 5 әр сум ала, бер көн эшкә чыкмаган өчен 3 көнлек эш хакын тотып кала иде. Моисеенко үзенең истәлекләрендә бер өйрәнчек „бер кисәк ярым бархет тапшырды, товар чыннан да яхшы эшләнгән һәм ул премия көтә иде“. Морозов, бу кисәкне карагач, „Яхшы, яхшы эшләнгән, аңа 50 тиен штраф языгыз, ул тагын да яхшырак эшләр“ [2])—дип язган.

1881 нче елдан 1884 нче елга кадәр вакыт эчендә Морозов фабрикасында штрафлар 155 процент артты. Хуҗа шуның өстенә, расчет кенәгәләре, паспортны яздыру, каморкаларны яктырту, мунча, дворник тоту, бәдрәфләрне чистарту, кубтан су алу, самоварга күмерләр, чиркәү өчен һәр төрле чигереп калулар белән эшчеләрнең теңкәсенә тия иде. Болар барсы да эшчеләрнең аннан башка да түбән хезмәт хакын тагын да киметә иде: тукучының хезмәт хакы 1884 нче елда көнгә уртача 41 тиен яисә айга 10 сум булды. Эш башыннан эшләү өчен шундый шартлар куйдылар ки, кайбер тукучылар айга 2 сум 50 тиеннән дә артык эшли алмадылар. Ләкин эшче шул аз гына хезмәт хакын да үз кулына ала алмады: черек продуктлар белән кредитка сәүдә иткән фабрика лавкасы эшченең актык тиеннәрен йолкып кала иде.

Хезмәт дисциплинасы крепостнойлык вактындагыдан аз аерылды. В. И. Ленин болай дип язды: „Крепостной крестьяннәр алпавытларга эшләделәр, һәм алпавытлар аларны җазаладылар. Эшчеләр капиталистларга эшлиләр, һәм капиталистлар аларны җазалыйлар.—Бөтен аерма шунда гына ки, элек ирексез кешене имән таяк белән кыйнаганнар, ә хәзер аны сум белән кыйныйлар“ [3]). Эшчеләрнең көнкүреш шартлары да шулай ук коточкыч иде. Аларның зур күпчелеге агач сәкеләрдән, өстәлдән һәм табореткадан башка бер нәрсәсе булмаган фабрика казармаларында яшәде. Ирләр һәм хатын-кызлар сәкеләрдә бергә йоклыйлар, һичбер төрле ятак әйберләре бирелми иде. Биналарда чиксез пычыраклык хөкем сөрә, бөтен ярыклар кандалалар һәм тараканнар белән тулы иде. Бу коточкыч яшәү урны булып, анда эшче коточкыч җазаларга дучар ителә иде.

Рус пролетарие—капиталистик эксплуатациянең изүе астында ыңгырашкан хокуксыз кол әнә шулай яшәде һәм эшләде.

1883 нче ел азагында Морозов фабрикасына яңа тукучы— „Рус эшчеләренең Төньяк союзы“н оештыруда катнашкан беренче рус революционер эшчеләренең берсе—Петр Анисимович Моисеенко (1852—1923) эшкә керде. Ул Плехановны, Халтуринны, Обнорскийны белә иде, 1876 нчы елда Казанский мәйданында демонстрациядә катнашты. 1878 нче елда текстильщик эшчеләрнең стачкасында катнашкан өчен Моисеенко кулга алынды һәм туган иленә сөрелде. Ә 1879 нчы елда Себергә Енисей губернасына сөрелде. Ул бары тик 1883 нче елда гына сөргеннән кайтты. Морозов фабрикасына эшкә кереп, Моисеенко „Рус эшчеләренең төньяк союзы“ның элекке члены Лука Иванов һәм энергияле яш иптәш Василий Волков белән бергә Морозов тукучылары арасында революцион пропаганданы һәм агитацияне җәелдерде. Иң аңлы тукучылар группасы белән бергә алар Морозовка таләпләр төзеделәр. Бу таләпләр 50 эшченең яшерен киңәшмәсендә расландылар. Моисеенко, Иванов һәм Волков стачканы әнә шулай хәзерләделәр. 1885 нче елның 7 нче гыйнварында [4]) иртән 6 сәгатьтә эшчеләрдән берсе алдан сөйләшеп кую буенча „Бүген бәйрәм, эшне бетерегез, газны сүндерегез“ дип кычкырды. Стачка башланды. Түзә алмаслык хәлгә килгән эшчеләр, Моисеенконың һәм Волковның алдан әйтеп куюларына да карамастан, кортлаган продуктлар куелган фабрика лавкасын җимерделәр, үзеннән нәфрәтләндергән мастер Шоринның квартирасын тар-мар иттеләр.

Бу „бунт“ администрацияне һәм хөкүмәтне гадәттән тыш куркытты. Орехово - Зуевога шул сәгатьтә үк гаскәрләр—ике батальон пехота һәм казаклар полкы килде, Владимирдан губернатор, прокурор һәм Москвадан прокурор килде. Губернатор стачканы кичекмәстән туктатуны таләп итте. Ләкин эшчеләр каушап калмадылар, фабрикантның шартларына күнмәделәр. Стачка ясаучылар белән сөйләшкән вакытта Волков электән төзелгән таләпләрне начальникларга тапшырды. Бу таләпләр: штрафлар, хезмәт хакының 5 процентыннан артмаска тиешләр, 1884 нче елның пасхасыннан бирле түләтелгән штрафлар кире кайтарылырга тиеш, эшкә чыкмый калган өчен чигереп калулар 1 сумнан артмаска тиеш, хуҗа үз гаебе буенча эшләнми торган вакыт өчен түләргә тиеш. Старосталарны ирекле рәвештә сайлауга юл куелырга тиеш һ. б. Эшчеләр губернаторга: „Без ярым ач йөрибез, эшләргә телибез һәм барырбыз, ләкин семьяләрне туйдырырга мөмкинлек бирегез“ дип белдерделәр.

Администрация ташлама ясауга бармады. 1885 нче елның 11 нче гыйнварында эшчеләр кызыл байраклар күтәреп демонстрация ясадылар. Александр III нченең үз приказы буенча стачка ясаучыларны массовый күләмдә кулга алулар башланды. Эшчеләрнең бер өлеше бер бинага ябылды, ләкин эшчеләр, ишекне ватып, чыгып киттеләр. Волковны кулга алган вакытта ул „Мин барыгыз өчен дә, яисә барыгыз да минем өченме“, дип кычкырды. Эшчеләр аңа „Барыбыз да, барыбыз“ дип бердәм җавап бирделәр һәм кулга алынучыларны казаклар кулыннан тартып алырга ташландылар. Бу эш барып чыкмагач, алар барсы да властьларга бардылар һәм „Васьканы, безнең кешене азат итегез“ дип таләп иттеләр.

Бары тик 8 көн барган каты көрәштән, казаклар һәм пехота белән берничә тапкырлар бәрелешләрдән соң гына Морозов тукучыларының героик каршылык күрсәтүләре бастырылды. Стачкага актив катнашкан 600 кеше кулга алынды һәм туган илләренә сөрелделәр. П. А. Моисеенко, Лука Иванов, Василий Волков һәм стачканың башка җитәкчеләре—барлыгы 33 эшче—присяжныйлар судына бирелделәр. Суд 1886 нчы елның маенда Владимирда булды. Судта шаһитләрнең, шул исәптән, Морозовның, фабрика директоры Диановның һәм күп эшчеләрнең күрсәтмәләреннән Морозов фабрикасында искиткеч тәртипләр яшәп килгәнлеге ачылды. Присяжныйларга 101 сорау бирелде, аларга присяжныйлар тарафыннан 101 кире җавап алынды. Хәтта патша суды да судка тартылган кешеләрнең барын да акларга мәҗбүр булды.

Морозов стачкасы бөтен Россия күләмендә әһәмиятле зур политик вакыйгә булды. Ул, Россиядә генә түгел, бәлки Көнбатыш Европада да көчле тәэсир калдырды. Ул бергә хәрәкәт итүче, үз таләпләрен кыюлык белән куючы һәм аларны үткәрергә тырышучы эшчеләрнең гаять зур көч булуын күрсәтте.

Стачка Александр III нчене һәм аның министрләрен куркуга төшерде. 1886 нчы елның 3 нче июнендә үк фабрика законы чыгарылды. Аның төп эчтәлеге хуҗаның штрафларны юлга салудагы баш-баштаклыгын бер кадәр чикләүдән торды. Закон штрафларны нинди хәлләрдә алырга рөхсәт ителгәнен күрсәтте. Штрафның иң күбе күпме булырга тиешлеген билгеләде һәм штраф акчаларын фабрикант кесәсенә түгел, бәлки эшчеләрнең үз ихтиаҗларына китәргә тиешлеген күрсәтте. Законның аерым статьяләрен Морозов тукучыларының 1885 нче елның гыйнвардагы таләпләре белән чагыштырганда, бу таләпләрнең байтагы канәгатьләндерелгән булуын күрергә мөмкин.

Фабрикантлар да эшчеләрнең көчен сизделәр. Эшчеләрнең таләпләре буенча аларның күбесе үз фабрикаларындагы тәртипләрне үзгәртергә тиеш булдылар.

Морозов стачкасы Россиядәге эшчеләр сыйныфының революцион көрәшен үстерүдә гаять зур әһәмиятле урын тотты. Ул торган саен оешканрак характер ала барып массовый эшчеләр хәрәкәтенең башлангычы булды. Эшчеләр коллектив рәвештә отпор бирү кирәклеген аңладылар һәм колларча буйсынучанлыкны кискенлек белән ташладылар. Морозов стачкасын ясаучыларның таләпләре аяныч ялварулар һәм сораулар түгел, бәлки яңа революцион сыйныфның властьлы сүзе булып яңгырады.

Морозов стачкасы эшчеләр белән хуҗалар арасында сыйнфи антоганизм уянганлыгын күрсәтте. Морозов стачкасын ясау белән Россиядәге эшчеләр сыйнфы яңа полосага керде һәм Плеханов язганча „Эшчеләр хәрәкәтенең яңа фазисының башланып китү пунктын билгеләде“.

Эшчеләр хәрәкәтенең тагын да үсүенә җитәкчелекне Маркс һәм Энгельс эшен даһи дәвам иттерүче В. И. Ленин ныклап үз кулына алды. Эшчеләрнең аерым стачкалардан массовый оешкан чыгышларга күчүләренә, хезмәт ияләрен патша хөкүмәте изүеннән, капитал изүеннән коткару өчен көрәшкә эшчеләр сыйнфының хәзер торуларына ирешү өчен, Ленин 90 нчы елларның башыннан гаять зур революцион эш алып барды. В. И. Ленин барлык аңлы эшчеләрне социалистлар итү өчен, хезмәт ияләренең азатлыкларына юл ачкан чын-чыннан революцион эшчеләр партиясен, большевиклар партиясен оештыру буенча гаять зур эш җәелдерде.

Даһи юлбашчы В. И. Ленин һәм аның бөек көрәштәше И. В Сталин җитәкчелегендә Россиянең эшчеләр сыйнфы, Маркснең „Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!“ дигән мәңгелек сүзләре язылган кызыл байракны күтәреп, барлык илләрдәге эшчеләрнең бөек хәрәкәтенең беренче сафларына килеп басты.

П. Н. Шарова.

Тарих фәннәре кандидаты.

[1]) „Русские Ведомости“ №1—1884 ел.

[2]) Моисеенко. „Истәлекләр“,1873—1923 нче еллар, 88 бит.

[3]) Ленин, том I, 366 бит.

[4]) Иске стиль буенча.

Комсомолның өлкә күләмендәге актив җыелышында. РӘСЕМДӘ: комсомол активы ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. П. Перовның докладын тыңлый.

Б. Невзоров фотосы.

Казан—Чистай—Бөгелмә трактын төзек һәм культуралы юл итик!

Столбище, Лаиш, Алексеевский, Чистай, Кызыл Армия, Яңа Писмән, Акташ, Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Бөгелмә районнарының барлык колхозчыларына, кохозчы хатын-кызларына, эшчеләргә, промысло артеле членнарына һәм барлык интеллигенциягә Столбище районы „13 лет Октября“ артеле колхозчыларының моражәгате

Революциягә кадәр булган Россия юлсызлык иле иде. Халык ул вакыттагы йөри алмаслык юллар турында бик күп мәкалләр чыгарды. Элекке юллардан җәяү дә, ат белән дә йөрү читен иде. Юлсызлык мирасы элеккеге Казан губернасында да зур иде, аның территориясендә „Земский“ юллар дип аталган, яхшыртылган юллар 80—90 километрдан артмады.

Хәзер инде алай түгел. Сталинчыл бишьеллыклар эчендә Татарстандагы юл хуҗалыгы бик күп алга китте. 4.426 километр профилле, яхшыртылган юллар, 1.992 километр таш түшәлгән юллар, 45.416 погон метр күперләр һәм күпер асты трубалары төзелде. Юл хуҗалыгы яхшы техника белән баеды; юл төзү эшендә йөз меңнәрчә алдынгылар үсте, алар бу тармакта стахановча эшлиләр.

Шулай булуга да карамастан, Татарстан әле дә төзек һәм культуралы юлларга бай республика түгел. Юлларның торышы хуҗалыкның үсеп бара торган таләпләрен үти алмый, чөнки безнең республикада тимер юл челтәре җитәрлек түгел әле.

Юлсызлык бик зур бәлә. Юлсызлык шәһәрләр белән авыллар арасындагы экономик һәм культура элемтәсен кыенлаштыра, предприятиеләрне һәм артельләрне чимал белән, ә потребительләрне товар белән нормаль тәэмин итүне боза, колхозчыларга үзләренең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен тизлек белән үтәүгә комачаулык ясый. Яраксыз юллар автомашиналарны, транспортны эштән чыгара, юлчыларга бик зур кыенлыклар китерә.

Моннан соң да юлсызлык хурлыгына түзеп буламы һәм үрнәк юлларга бай булган Чувашстан һәм аның кебек башка республикалардан артта калып барырга ярыймы? Юк, ярамый. Мондый хәл орденлы Татарстан хезмәт ияләренә ярый торган нәрсә түгел.

Күптән түгел генә Ярославль өлкәсенең хезмәт ияләре үзләренең юлларының торышы турындагы мәсьәләне тикшереп, юлсызлык белән килешә алмау фикрен әйттеләр. Алар Үзбәкстанда иптәш Сталин исемендәге Зур Фирганә каналын иң кыска срокларда төзүнең гүзәл тәҗрибәләрен юл төзү эшендә куллануга күчерүнең инициаторлары булдылар. Ярославль өлкәсе хезмәт ияләре яхшы юлларның тормыш өчен никадәр әһәмиятле булуын яхшы аңладылар. Һәм фирганәчеләр методы белән Ярославль—Рыбинск арасындагы трактны—юлны үрнәк итеп төзү эшенә уңышлы рәвештә хәзерләнәләр.

Бу гүзәл үрнәк Татарстан колхозчылары тарафыннан да эләктереп алынырга тиеш. Бездә даими юл төзү бригадалары булган алдынгы колхозлар аз түгел, алардагы юл төзү бригадалары вакыт белән хисаплашмыйлар, актив рәвештә эшлиләр.

Столбище районындагы безнең „13 лет Октября“ колхозы юл төзү планын һәр вакытта арттырып үти. Ләкин кайбер урыннарда әле юл төзү эшенә бик аз игтибар итәләр, аны икенче дәрәҗә эш итеп исәплиләр. Шуның нәтиҗәсендә, алдынгы авыл советлары һәм колхозлар тарафыннан төзелгән, таш түшәлгән юл участкылары кинәт өзеләләр дә, үтә алмаслык участкыларга барып керәсең. Шуннан соң юл тагын берникадәр яхшы бара, тагын бозыла һәм башкалар. Мондый үтә алмаслык участкылар Татарстанның иң әһәмиятле трактларында кай чагында 20—25 километрга сузыла, автомашиналарның һәм атлы транспортның нормаль йөрешен боза. Без Фирганә тәҗрибәсен иң элек республикабызда дәүләт өчен һәм урыннар өчен әһәмиятле булган төп юлларны тоташтан йөрердәй, төзек иттереп коруга юнәлдерергә кирәк дип саныйбыз. Чкаловск тракты (Казан—Чистай—Бөгелмә) 337 километрга сузыла һәм бу тракт республикадагы иң әһәмиятле юлларның берсе. Бу тракт транспортның төп нервы булып тора. Ул бөтен Татарстанны төньяк - көнбатыштан көньяк-көнчыгышка үтеп чыга, 20 дән артык районны республикабызның үзәге белән тоташтыра. Анда йөк ташу обороты бик зур. Бу трактның күп кенә участкыларында җәй көннәрендә тәүлеккә 400—500 автомашина үтә. Бу юлда атлы транспорт йөреше дә көчле.

Аннары Чкаловск тракты тимер юл станцияләре булган Казанга, Бөгелмәгә һәм пристане булган Лаиш, Мурзиха һәм Чистай шәһәрләре белән, бик күп элеваторлар белән тоташа. Бу авто-ат транспортының экономик әһәмияте, аның Чистай шәһәре аркылы үтүе белән тагын да зурая. Чөнки Чистай шәһәренең киләчәге нефть табу белән, машина төзелеше һәм башка промышленность предприятиеләренең үсүе белән бәйләнгән.

Казан—Бөгелмә трактының 252 километрына таш түшәлгән, ә 85 километры исә гади юлдан гыйбарәт. Менә бу 85 километрны шоссегә яки чуер таш белән капланган юлга әйләндерергә кирәк. Без Столбище, Лаиш, Алексеевский, Чистай, Кызыл Армия, Яңа Чишмә, Акташ, Әлмәт, Яңа Писмән һәм Бөгелмә районнарының партия һәм совет оешмаларын үз районнарындагы барлык хезмәт ияләрен шушындый зур һәм әһәмиятле эшкә—Чкаловск трактын тулы тәртипкә китерү эшенә тупларга чакырабыз. Моны үтәү өчен бу юлга 40 мең кубометр төзү материаллары ташырга, 174 мең кубометр җир казу эшен башкарырга, 500 погон метр күпер һәм күпер асты трубалары төзергә кирәк. Яңа төзелештән тыш миллион ярым сум күләмендә капиталь һәм агымдагы ремонт эшләрен башкарырга кирәк.

Бу кечкенә эш түгел, ләкин 10 районнардагы хезмәт ияләренең берләшкән көче белән, стахановча бердәм эшләү белән бу эшне иң кыска срокларда үтәргә мөмкин. Эшнең зур күләмен (22 километр) безнең Столбище районы башкарырга тиеш булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Димәк, безнең районга аеруча зур җаваплылык төшә. Юллар өзелгәнгә чаклы хәзерлек эшләрен тәмам итү өчен, төзү материалларын хәзерләү һәм участкыларга ташу эшенә хәзер үк, кичекмәстән керешергә кирәк. Юл күперләренә ремонт ясауга һәм яңаларын төзүгә хәзер үк керешергә кирәк. Бу объектлар авыл хуҗалыгының язгы эшләренә кадәр эшләнеп бетәргә тиеш. Ә магистральне тулысынча тәртипкә китерү эшен исә урып-җыю кампаниясенә кадәр төгәлләргә кирәк.

Казан—Бөгелмә тракты төзек һәм культуралы юл булсын өчен анда автомашиналар өчен ягулык алу пунктлары төзергә, пассажирлар ял итү өчен павильоннар булдырырга һәм юл буйларына агачлар утыртырга кирәк. Шулай итеп эшләгәндә 1940 нчы елның җәендә Татарстан 15 миллион сум торырлык төзек юл алачак! Бу юл орденлы республикабызның 20 еллык бәйрәме көненә иң зур бүләк булыр!

Иптәшләр, һич кичекмичә эшкә керешик, районнар, авыл Советлары, колхозлар һәм юл төзү бригадалары арасында социалистик ярышны җәеп җибәрик. Безнең „13 лет Октября“ колхозы барлык төзү материалларын 15 нче февральгә кадәр ташып бетерүне өстенә ала һәм Казан — Бөгелмә трактын төзү эшендә актив рәвештә катнашырга сүз бирә.

Зур Фирганә тәҗрибәсе, халык хәрәкәте белән барлыкка китерелгән зур эш безнең күз алдыбызда. Бөек юлбашчыбыз, остазыбыз, илебезнең беренче стахановчысы иптәш Сталин халык хуҗалыгының барлык тармаклары турында, аерым алганда юл төзелеше турында зур кайгыртучанлык күрсәтә.

Республикабыздагы юлсызлык хурлыгын бетерик! Татарстанның барлык шәһәрләрен, районнарын, авылларын үрнәк һәм культуралы юллар белән тоташтырыйк!

Столбище районы, „13 лет октября“ колхозында үткәрелгән гомуми җыелыш тапшыруы буенча:

Шигаев С. Е. Гаврилов Е. Л.
Клин И. С. Хренов П. Т.
Жуков П. А. Сергина М. Ф.
Громков В. П. Никитин И. К.
Шигаев И. А. Мартюхин П. Т.
Громков В. Л. Шигаев В. Е.
Шигаева М. В. Сокончиков Г. А.
Гришагина А. Е. Павлинов И. Д.
Хренов В. П. Паньков Д. Г.
Новиков Д. А. Муравьев А. Н.
Мальцев А. С.
Громков Ф. В.
Павлинов В. П.

Кадрлар хәзерләүгә игтибар бирмиләр

Соңгы елларда безнең республикабыз умартачылык эшендә дә шактый зур уңышларга иреште. Киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешү өчен бездә мөмкинлекләр зур. Ләкин моның өчен, барыннан да элек, квалификацияле кадрлар хәзерләргә кирәк. Ә алар бездә һич тә җитәрлек түгел әле. Татнаркомзем да һәм шулай ук кайбер район җир бүлекләре дә умартачы кадрлар хәзерләүгә җитәрлек игтибар бирмиләр. Балтач район колхоз мәктәбендә умартачылыкка 35 кеше урнына бары 13 кеше, Кукмара район колхоз мәктәбендә 35 кеше урнына бары 20 кеше укый. Бу мәктәпләргә курсантлар җибәрүгә Кукмара, Мамадыш, Дөбъяз, Чепья һәм Әтнә районнары бөтенләй игтибар бирмиләр. Бу районнардан курсларда бары берәр генә кеше укый.

Югарыда күрсәтелгән мәктәпләрнең кайберләрендә укучылар өчен уңайлы шартлар булдыруга да игтибар бирелми.

Г. Хәкимов.

В. И. Ленин музее-йортында (Казан). РӘСЕМДӘ: Ульяновлар семьясенең ашханәсе. Б. Мясников фотосы. (ТатТАСС фотохроникасы).

ЛЕНИН КӨННӘРЕ АЛДЫННАН

Москваның Свердлов районында В. И. Лениннең үлүенә 16 ел тулу көнен үткәрүгә хәзерлек киң җәелде. Районның предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә, уку йортларында, театрларда, өйләрдә һәм тулай торакларда, элекке сайлау участкыларында Владимир Ильич Лениннең тормышы һәм эше турында докладлар, лекцияләр, беседалар үткәрелә.

ВКП(б) райкомы 100 гә якын докладчылар билгеләде. Докладчылар, агитаторлар һәм беседа үткәрүчеләр өчен инструктив доклад оештырыла.

Каляев исемендәге клубта, „Известия" комбинаты типографиясендә, СССР Наркомлесында, Зур Дәүләт театрында Владимир Ильичнең тормышына һәм эшенә багышланган фото-күргәзмәләр оештырыла.

Районның предприятиеләре һәм учреждениеләре В. И. Ленинга багышланган күп тиражлы газеталар һәм стена газеталары чыгаралар.

Районда „ВКП(б) һәм халыкларның юлбашчысы иптәш Сталин җитәкчелегендә Владимир Ильич Лениннең васыятьларын үтәү" дигән темада докладлар белән тантаналы-траур җыелышлары үткәрелә башлады.

СИМФЕРОПОЛЬ, (ТАСС). Шәһәрнең предприятиеләрендә, учреждениеләрендә Ленин көннәренә зур хәзерлек бара. Шәһәрнең партия мәгарифе йортында В.И. Лениннең тормышын һәм революцион эшен чагылдыра торган фото-әдәбият күргәзмәсе оештырылды. Соңгы вакытта партия мәгарифе йортына йөрүчеләр күбәйде, Ленин һәм Сталин әсәрләренә сорау артты.

Кырым дәүләт издательствосы Кырым татарлары телендә 48 мең данә тираж белән В.И. Ленин әсәрләрен басып чыгара.

ЯКУТСК, (ТАСС). Якутскийның, Алданның, Верхоянскийның 800 дән артык агитаторы хәзер предприятиеләрдә, колхозларда һәм элекке сайлау участкыларында революциянең бөек даһие В. И. Лениннең тормышы һәм эше турында беседалар үткәрәләр.

Якутскийның үзәк фәнни китапханәсе „Лениннән башка, Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы белән 16 ел" дигән темага күргәзмә хәзерли. Өлкә издательствосы Ленин көннәренә Владимир Ильичнең 1905 нче елгы революция турындагы мәкаләләре җыентыгын якут телендә басып чыгара.

ЛЕНИН МАВЗОЛЕЕ ЯНЫНДА

Кызыл мәйданда Кремль стеналары янында бөек мавзолейдә Владимир Ильич Лениннең гәүдәсе саклана. Мавзолей ишеге төбендә почетлы караул.

Һава нинди генә булса да мавзолей янында һәр вакыт халык күп була. Бөек илебезнең барлык почмакларыннан башкалага хезмәт ияләре килә. Алар барсы да иң элек мавзолейдә булырга омтылалар.

Алар барсы да биредә бөек кабер алдында башларын иярга, дөньяда беренче социалистик дәүләтнең атасы—даһи Лениннең йөзен хәтерләрендә калдырырга киләләр.

1924 нче елдан бирле Мавзолейдә 16 миллионнан артык кеше булды. 1939 нчы елны гына да мавзолейгә килүчеләрнең саны 2,3 миллионнан артты. (ТАСС).

Ленин турында фото-газета

Совет Сәүдә Работниклары клубы бүген, 18 нче гыйнварда, Сәүдә Работниклары балаларының Ленинне искә алуга багышланган иртәлеген үткәрә. Балалар иртәлегендә Владимир Ильич турында беседа булачак. Соныннан „Ленин 1918 нче елда" дигән кино-фильм күрсәтелә.

Клубның партия кабинетында Ленин почмагы җиһазландырылды. Биредә Ленин әсәрләреннән китап күргәзмәсе һәм иптәш Сталинның Ленин үлгәннән соң биргән анты куела. Фото-газетаның Ленинга багышланган махсус номеры хәзерләнә.

20—21 һәм 22 нче гыйнварда клубта йорт хозяйкалары һәм сәүдә работниклары өчен докладлар белән В. И. Ленинне искә алу кичәләре үткәреләчәк. Бу кичәләрдә клубның үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан тематик концерт биреләчәк.

В. И. Ленин хезмәтләрен кызыксыну белән өйрәнеләр

Соңгы вакытта Казан Авыл Хуҗалыгы Институтында В. И. Ленин әсәрләрен өйрәнүчеләрнең саны шактый артты. Лениннең „Бер адым алга, ике адым артка" дигән китабын студентлардан һәм фәнни работниклардан 50 дән артык кеше өйрәнә. „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы" дигән китапны 40 тан артык кеше, „Дәүләт һәм революция" китабын 30 га якын кеше өйрәнә.

Студентлар һәм фәнни работниклар Лениннең „Нәрсә эшләргә?" дигән китабын өйрәнүгә дә зур игтибар бирәләр.

Чит илләрдә

АНГЛИЯ—ФРАНЦИЯ БЛОГЫНЫҢ СКАНДИНАВИЯНЕ СУГЫШКА ТАРТЫРГА МАТАШУЛАРЫ ТУРЫНДА ГЕРМАНИЯ МАТБУГАТЫ

БЕРЛИН, 15 гыйнвар (ТАСС). Скандинавия илләренең Германия белән мөнәсәбәтләренә матбугат зур әһәмият бирә.

„Данцигер фарпостын" газетасы, Германиянең төньякка мөнәсәбәте турындагы мәсьәлә бөтен дөнья матбугатының игтибар үзәгендә тора, дип яза.

Скандинавия матбугаты артында,—ди газета,—Англия яшеренгәнлекне күпләр аңламыйлар. Шунлыктан Скандинавия матбугатында Совет—Германия дуслыгына каршы һәр төрле һөҗүмнәрне табарга мөмкин булуы гаҗәп түгел. Скандинавия газеталарының позициясе Англиянең төньяктагы чын планнарын яшерүенә булышлык итүне максат итеп куя, күрәсең. Англия Швецияне һәм Норвегияне „Германия куркынычы" белән куркытырга омтыла. „Финляндиягә ярдәм" сылтавы астында Англия Скандинавия илләреннән аэродромнар өчен территорияләр алырга тырышып кына калмый, бәлки төньякның руда һәм урман байлыклары белән дә кызыксынганлыгын күрсәтә.

Ахырда газета төньяк илләрнең җаваплы җитәкчеләрен „ялган пәрәвезен үтеп чыгарга һәм Англиянең чын максадларын аңларга" чакыра.

„Кльнише цейтунг" газетасы, Англия һәм Франция „Финляндиягә ярдәм" флагы астында үз интересларын тәэмин итәргә маташалар,—дип яза. Англия матбугатының белдерүләренә караганда, „Финляндиянең җиңелүе Англиягә һәм Франциягә стратегия ягыннан гаять зур зарар китерәчәк. „Финляндиягә ярдәм" кампаниясенең чын сәбәпләре әнә шунда ди газета. „Женеваның мораль идеаллары" турындагы бөтен сөйләнүләр Скандинавияне басып алу һәм аны сугышның яңа плацдармына әйләндерү теләген яшерергә тиешле маневр гына булып торалар.

ДАНИЯ ЭШЧЕЛӘРЕ ФИН АК ГВАРДИЯЧЕЛӘРЕНӘ ЯРДӘМГӘ КАРШЫ

КОПЕНГАГЕН, 16 гыйнвар. Соңгы көннәрдә Дания матбугатында эшчеләрнең күп кенә хатлары иглан ителде. Алар, профсоюзларның кайбер җитәкчеләренең ак финнәргә „ярдәм күрсәтү" флагы астында оешмалардагы кассаларны урлауларына каршы протест белдерәләр. „Арбейдербладет" газетасының соңгы номерларыннан берсендә эшче Сигурд Нильсен болай яза: „Арбейдербладет"ның якшәмбе көн чыккан номерында, кара эштә эшләүчеләр союзы җитәкчелегенең ак финнәргә союз акчаларыннан 40 мең кронны законсыз рәвештә бирүенә каршы эшче Хельмут Ульсенның протесты иглан ителгән иде. Мин бу протестка тулысынча кушылам һәм союзның җитәкчеләренә сорау бирәм:—Кассада шундый зур күләмдә артык сумалар кинәт кенә каян килеп чыкты? Бу акчалар—союз членнарының акчалары, аларның членлык взнослары. Ул акчаларның кечкенә хезмәт хакы алучы эшчеләрнең нинди хезмәтләре белән җыелганлыгын без беләбез. Дания эшчеләренең акчаларын Англия империалистлары күрсәтүе белән алып барыла торган сугышка ярдәм өчен тотуга каршы протест белдерәм. Ак финнәргә җитәкчелектә канлы Маннергеймның торуы—шушы факт үзе генә дә үзе өчен үзе сөйли. Фин халкының бу палачы һәм аның шикелле кешеләр демократия өчен көрәшәләр, дигән нәрсәгә ышанырга мине берәү дә мәҗбүр итә алмас. Даниянең башка эшчеләре шикелле үк мин дә, шушы ак гвардиячеләр бандасы файдасына „иганәләр" җыюга һәм эшчеләрне талауга чиксез дәрәҗәдә ачу белдерәм". (ТАСС).

Маннергейм диктатурасы турында фин качаклары

ОСЛО, 16 гыйнвар. Маннергейм бандалары тарафыннан көчләп үзләренең туган җирләреннән куылган фин качакларының гадәттән тыш авыр хәлләре турында Скандинавия матбугатында көн саен иглан ителә. Норвегиядә чыга торган „Арбейдерен" газетасының төньяк Норвегиядәге хәбәрчесе болай дип яза: „Мин, ак фин сугыш чукмарлары тарафыннан көчләп Финляндиядән куылган олы яштәге кешеләр белән сөйләштем. Алар үзләрен сөрелүгә дучар иткән канлы Маннергейм диктатурасы турында ачу һәм нәфрәт белән сөйлиләр. Качаклар хәрби властьларның аларның йортларын яндырганлыкларын, ә үзләрен көчләп куып алып киткәнлекләрен сөйлиләр".

Хәбәрче, сүзендә дәвам итеп, болай ди: „Бу качакларның теләкләре бер генә—алар үзләренә дошман булган ак финнәр „хөкүмәтенең" мөмкин кадәр тизрәк бәреп төшерелүен, бөтен илдә властьның халык хөкүмәте кулына күчүен һәм бу хөкүмәтнең тынычлык урнаштыруын һәм хезмәтчел халыкның демократик хокукларын урнаштыруын телиләр. Ул вакытта алпавытлардан азат ителгән вак крестьяннар һәм урман эшчеләре туган җирләренә кайтачаклар, бәхетле, ирекле яңа тормыш башлаячаклар". (ТАСС).

БЕЛЬГИЯДӘ КОММУНИСТЛАР МАТБУГАТЫНА КАРШЫ РЕПРЕССИЯЛӘР

ПАРИЖ, 16 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы Брюссельдән түбәндәге хәбәрне тапшыра: „Бельгия хөкүмәте коммунистик газеталар нинди генә исем белән чыксалар да аларны тыю турында карар чыгарды". (ТАСС).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуандун провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре японнарның чигенеп баручы частьләрен эзәрлекләүне дәвам иттерәләр. Кытайларның алдынгы колонналарыннан берсе Кантоннан төньяк-көнбатышка таба 20 километрда урнашкан япон позицияләренә һөҗүм итә. Кантоннан төньякта, Синьцзяюй районында, япон гаскәрләре каты сугыштан соң үзләренең позицияләреннән чигенделәр. Аларның 500 дән артык кешесе үтерелде. Кытай гаскәрләре күп санда корал һәм амуниция яулап алдылар. Алар арасында 4 кыр орудиесе һәм станоклы 9 пулемет бар.

Гуанси провинциясендә соңгы ике көн эчендә японнарның пехота отрядлары, авиация ярдәме белән, Наньниннан ерак түгел бер урында кытайларның позицияләренә атака ясарга маташтылар. Японнарның барлык атакалары кире кайтарылды. 15 нче гыйнварда кытай гаскәрләре һөҗүмгә күчтеләр һәм, японнарны позицияләреннән кысрыклап, Наньниннан төньяк-көнчыгышка таба 20 километрда урнашкан пунктка барып җиттеләр.

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясендә кытай гаскәрләре актив операцияләрне яңарттылар, күп кенә пунктларны алдылар һәм Пуцинның көнчыгыш бистәләрендә японнарның позицияләренә якын ук килеп җиттеләр. Провинциянең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре Иншаньнан төньякта Шилипу тирәсендә японнарның отрядына атака ясадылар. Японнарның 400 гә якын кешеләре үтерелде һәм яраланды.

Төньяк Кытай фронтларындагы хәл турында мәгълүматлар юк.

16 гыйнвар.

ЯПОНИЯ ИМПЕРАТОРЫ ЯҢА КАБИНЕТ СОСТАВЫН ЯХШЫ ДИП ТАПТЫ

ТОКИО, 16 гыйнвар. Домей цусин агентлыгы радио буенча болай дип хәбәр итә: бүген Япония императоры премьер Ионай тарафыннан төзелгән яңа кабинет составын яхшы дип тапты.

Сәүдә һәм промышленность министре итеп Фудзивара Гиндзиро (промышленникларның бөтен Япония федерациясе председателе) билгеләнде. (ТАСС).

АМЕРИКА КОНГРЕССЫ СЕССИЯСЕНДӘ

ВАШИНГТОН, 16 гыйнвар. Хәрби-диңгез флотына кораллар һәм сугыш кирәк-яраклары хәзерләү өчен өстәмә рәвештә 31 миллион доллар акча җибәрүне сорап, Рузвельт конгресска мөрәҗәгать итте. Үткән ел бу эшкә 46 миллион доллар акча җибәрелгән иде. (ТАСС).

ХЕЗМӘТ ХАКЫ ФОНДЫНА КОНТРОЛЬ БУЛДЫРЫРГА

Промышленностьта хезмәт хакы фондының дөрес тотылуын контроль астына алу турында СССР Халык Комиссарлары Советының 1939 нчы ел 15 нче август карарын тормышка ашыру нигезендә, республикабызның күп кенә предприятиеләре шактый уңышларга ирештеләр. Мәсәлән, Татарстанда 1939 нчы елның сентябрь аенда 136 предприятиедә хезмәт хакы фонды 1 миллион 802 мең сум артык тотылган булса, ноябрь аенда инде 121 предприятиедә хезмәт хакы фонды 898 мең сум артык тотылган. Димәк, хөкүмәт карарыннан соң хезмәт хакы фондын артык тотулар шактый кимегән.

Производство планнарын үтәмәү—хезмәт хакы фондының артык тотылуының төп сәбәпләреннән берсе. Соңгы айларда аерым предприятиеләр планны үтәүдә кискен борылыш ясадылар. Мәсәлән, планны үтәү буенча артта калып килгән ясалма каучук заводы яхшы гына эшли башлады һәм ноябрь аенда хезмәт хакы фондына 109 мең сум экономия ясады.

Мехкомбинат, Вахитов исемендәге жиркомбинат, киез итек һәм „Спартак" фабрикалары, шулай ук 3 нче һәм 10 нчы номерлы фанер заводлары 1939 нчы елның ноябрь аенда хезмәт хакы фондыннан бер сум да артык тотмадылар. Ләкин җирле промышленность наркоматының кайбер предприятиеләре һәм Татпромсоветның күп кенә артельләре производство программасын тулы үтәмәүләре аркасында, хезмәт хакы фондын күп артык тоттылар. Мәсәлән, „Урак һәм Чүкеч" заводы узган елның ноябрь аенда производство планын 79 процент кына үтәде, ә хезмәт хакы фондын 60 мең сумга артык тотты. „Прогресс", „Татгармоника", „Красный Дорожник", „Кустарь", „Казпищепром" артельләрендә дә шундый ук хәл.

Октябрь районындагы леспромхоз күп вакытлардан бирле тирән өзеклектә тора. Бу леспромхоз октябрь аенда планны 48,8 процент, ноябрь аенда 61 процент кына үтәгән. Шуңа карамастан, шул ике айда хезмәт хакы фондын 157 мең сум артык тоткан. Дәүләт банкысының Октябрь районы бүлегенең управляющие Иванов һәм баш инспектор Волков иптәшләр леспромхозда мондый бозуларга чик куймаганнар.

Контрольсезлек бер монда гына түгел. Дәүләт банкысының Татарстан конторасы тарафыннан урыннарда үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә, аның күп кенә районнардагы бүлекләренең хезмәт хакы фондын тотуга җитәрлек контроль ясамаулары беленде. Мәсәлән, Дәүләт банкысының Чистай, Югары Ослан район бүлекләре моңа ачык мисаль була алалар.

Расланган фондларның үз вакытында урыннарга җиткерелүе хезмәт хакы фондын артык тотуларга каршы көрәштә гаять зур урын тота. Ләкин күпчелек наркоматлар хезмәт хакы фондларын һәм производство заданиеләрен урыннарга бик кичегеп җибәрәләр. 1940 нчы елның беренче кварталы өчен хезмәт хакы фонды әле бер генә наркомат буенча да урыннарга җиткерелмәгән.

Хезмәт хакы фондының дөрес тотылуын нык контроль астына алу предприятиеләрдә производство планын үтәү өчен зур этәргеч булып хезмәт итә. Бу контрольне тормышка ашыру дәүләт банкысы работникларына зур җаваплылык йөкли.

Ләкин моны кәгазьгә язылган мәгълүматлар буенча гына эшләргә ярамый. Предприятиеләрнең үзләренә барып тикшерү иң яхшы метод санала. Бу метод исә бездә бик аз кулланыла. Шуның нәтиҗәсендә, урыннарда закон бозуларны күп очратырга туры килә. Мәсәлән, мехторгның скорняк-тегү мастерскоенда (директоры иптәш Максимов) план үтәлешен 8—9 процентка арттырып күрсәтеп, хезмәт хакы исәбенә банктан артык акча алу факты булды. Куйбышевтагы судноларга ремонт ясау заводында бөтенләй башка статьялардагы акчаларны хезмәт хакына түләп килгәннәр.

Хезмәт хакы фондының дөрес тотылуын тикшерү эше җаваплы эш. Моны уңышлы үтәү өчен дәүләт банкысының район бүлекләренә зур ярдәм күрсәтелергә тиеш. Аларның аппаратларын ныгытырга, эшләрен юлга салып җибәрүгә булышлык итәргә, ВКП(б) райкомнары бюроларында, район Советларының башкарма комитеты президиумнарында аларның докладларын тыңларга һәм кирәк урында аларның эшләренә практик ярдәм күрсәтергә кирәк.

А. Сабитов.



РӘСЕМДӘ: Калмык халкы эпосы „Җангәр" нең юбилей басмасына художник В. Фаворскийның иллюстрациясе—эпосның төп герое баһадир Конгор. Г. Широков фотосы (ТАСС фото-клишесе).

„ҖАНГӘР"

1940 нчы елның маенда СССР халыклары тагын бер зур культура бәйрәме уздырачаклар. Бу бәйрәм калмык халкының бөек эпосы булган „Җангәрнең" 500 еллыгына багышланачак.

„Җангәр" бер кереш һәм 12 зур җырдан тора. Анда 13 меңнән артык шигырь юлы бар. Үзенең художество югарылыгы белән ул „Илиада", „Одиссея" һәм „Сасунлы Давид" шикелле әсәрләр белән бер дәрәҗәдә тора.

Эпопиянең беренче ике җыры 1856 нчы елны Казан университеты профессоры Бобровников тарафыннан русчага тәрҗемә ителә. 1910 нчы елны атаклы бәетче Овла Эллева әйтеп торуы буенча 10 җыры язылып алына. Ләкин бу бөек иҗад җәүһәрен чын-чынлап өйрәнү эшенә Советлар властьы вактында гына керешелә. Шагыйрь Липкин рус телендә „Җангәр" нең тулы тәрҗемәсен бирә. Совет галимнәре эпоска үзләренең мәкаләләрен багышлыйлар.

„Җангәр" дә калмык халкының иң якты уйлары чагыла. Анда патриотизм, гуманизм хисләре аеруча зур урын тоталар.

„Җангәр" Бумба иле турында җырлый. Бу—мәңгелек яшьлек, мәңгелек бәхет иле. Монда кешеләр үлмиләр дә, картаймыйлар да—25 яшьлек кешеләр булып кына яшиләр.

Халык үзенең батырларын егетлек, зирәклек, намуслылык һәм ватанга мәхәббәт тойгылары белән баетып бирә.

— Балалар ватанга ышанычлы терәк булыр өчен туалар!

Эпостан алынган бу сүзләр әсәрнең нинди изге идея белән сугарылуын аңлаталар дип уйлыйм.

„Җангәр" дә „Баһадирлар аиты" шикелле укып туйгысыз искиткеч шигъри һәм бөек фикерле урыннар гаять күп.

„Җангәр" нең 500 еллыгын уздыру өчен бөтен Союз күләмендә юбилей комитеты оештырылды. Күптән түгел Москвада шул комитетның беренче пленумы булып узды. Пленум СССР фәннәр Академиясенең, Гослитиздатның һәм урыннардагы юбилей комитетларының докладларын тыңлады.

Озаклямый рус һәм калмык телләрендә „Җангәр" нең тулы яңа басмалары һәм эпоска багышланган җыентыклар чыгачак.

Татарстан Совет Язучылары Союзы тарафыннан оештырылган юбилей комитеты да эшкә башлады. Татар совет шагыйрьләре бәйрәм көннәренә бөек эпосның татар телендә аерым җырларын бирәчәкләр.

Г. Кутуй.

АЛДЫНГЫЛАР БҮЛӘКЛӘНӘЛӘР

Үткән ел „Активист" (Норлат районы) колхозы колмактан зур уңыш алды. Колхоз колмак сатып 8.500 сум доход җыйды. Колмакчылыкта яхшы эшләгән колхозчылардан бригадир Хикмәтуллин 300 сум, звеновод Габсаттарова 100 сум, колхозчы Хәфәзә Яруллина 100 сум акча белән бүләкләнделәр.

Колхоз быел да колмакчылыктан мул уңыш алырга җыена. Моның өчен җир минераль ашламалар белән ашлана.

А. Җәләл.

СУГЫШЧЫЛАРГА БҮЛӘКЛӘР

Язу машиналары заводы эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре арасында Ленинград Хәрби Округының данлыклы сугышчыларына бүләкләр җинау киң күләмдә бара.

16 нчы гыйнварда инструменталь, җыю, механика һәм ремонт-механика цехларында, техник бүлектә һәм завод идарәсендә 3 сәгать эчендә 3.355 сум акча җыналды.

УРМАНДА КИНО

Урман промышленносты эшчеләренә культура хезмәте күрсәтү өчен урман һәм сал агызу работникларының Өлкә Комитеты 1939 нчы елны тавышлы өч күчмә автокиноаппарат сатып алды. Бу аппаратлар Ширәмәт, Октябрь, Чирмешән, Шәмәрдән, һәм Казан леспромхозларында эшләүчеләргә хезмәт күрсәтәләр. Бу елның беренче кварталында Шәмәрдән леспромхозы стационар тавышлы киноаппарат алачак.

ЭШЧЕЛӘР ӨЧЕН ЯҢА ЙОРТЛАР

Чаллыдагы кисмәк ясау мастерское үз эшчеләре өчен ике яңа йорт салдырды. Аларны төзү һәм җиһазлау өчен 21.600 сум акча тотылды.

Хәзер мастерской конторасы һәм кызыл почмак өчен ике катлы йорт төзүгә хәзерлек бара. Бу эшкә 34.800 сум акча билгеләнде. (ТатТАСС).

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

7 нче февраль, кич 5 сәгатьтә Казан Дәүләт Ветеринария институтының патологик анатомия кафедрасы аудиториясендә институт гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм ветеринария фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен, Кыргызстан Авыл Хуҗалыгы институтында профессор хезмәтләрен үтәүче В. П. Тульчинская тарафыннан „Зәңгәр тестоге туберкулез палочкаларын өйрәнүгә карата материаллар" дигән темада халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ

үткәрелә

Рәсми оппонентлар: профессор доктор М. В. Рево, профессор доктор Н. П. Рухлядев һәм профессор доктор Б. Л. Мазур.

Диссертация материаллары белән институт китапханәсендә танышырга мөмкин. 102—1

Казан Дәүләт Медицина институтының тире авырулары клиникасындагы

косметика һәм гигиена КАБИНЕТЫНДА

(Толстой урамы, 4, телефон 33—79) сыткыларны, бетчәләрне, сипкелләрне, миң, сөял кебек тиредәге төрле кимчелекләрне дәвалау, биткә массаж ясау, тирене тәрбияләү, чәчне дәвалау һәм доцентлар тарафыннан консультацияләр бирү эшләре алып барыла.

Кабул итү—түләүле, гомуми ял көннәреннән башка һәр көн көндез 4 сәгатьтән кич 7 гә кадәр. 2427—1

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

18 нче гыйнварда көндез һәм кич

ТУКАЙ

Талоннар: көндез 98, кич 99.
19 нчы гыйнварда (талон 100)

КЫЮ КЫЗЛАР

20, 21 һәм 22 нче гыйнварда спектакльләр булмый.

23 нче гыйнварда КҮЗЛӘР Талон 101.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген көндез һәм кич

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Талоннар: көндез 16, кич 79.

20 һәм 21 нче гыйнварда

МАСКАРАД

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген көндез 12 сәгатьтә һәм кич зур программа буенча цирк уеннары.

Москва 4 нче труппасының гастрольләре

ИНТЕРМЕДИЯ

ЧИК ЙОЗАКТА

Кич 8 дә башлана.

АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы

ЗОЛОТО гастрольләре

Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы художестволы яңа фильм ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	Инженер Кочинның ялгышуы
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	ЦИРК
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9-30 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (Икенче сериясе)

КИРӘК:

Главлесосбытның Казан конторасына, Татарстан һәм Чувашстан республикалары районнарында даими рәвештә эшләү өчен БРАКЕРЛАР. Казан, Колхоз урамы, 13. Телефон 13—65. 93—2—1

„Химзаготлес" трестының агач материаллары хәзерләү буенча өлкәара Казан конторасына, ашыгыч рәвештә, контора аппаратында эшләү өчен ӨЛКӘН РЕВИЗОР, Мари АССР һәм Киров өлкәсе районнарында эшләү өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЛАРЫ һәм БУХГАЛТЕРЛАР. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Зур урам, 62. Баш бухгалтерга килергә. Телефон 42—06. 92—3—1

Казан Шәһәр Трамвай Идарәсенә, вагоннар депосында ТРАМВАЙ ВАГОННАРЫНА РЕМОНТ ЯСАУ БУЕНЧА СЛЕСАРЬЛЫК ЭШЕНӘ ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН ГАДИ ЭШЧЕЛӘР. Ялгыз эшчеләргә тулай торакта урын бирелә. Трамвай идарәсенә 6 нчы бүлмәгә килергә. 91—1

С. М. Киров исемендәге Казан Химико-Технология институтына МАШИНИСТКАЛАР, СЛЕСАРЬЛАР, ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, КОЧЕГАРЛАР һәм ПОДКИДЧИКЛАР, КИЕМ ЭЛГЕЧЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, автомашиналарда эшләү өчен грузчиклар, ПЫЯЛА КАБАРТУЧЫЛАР, укыту бүлеге өчен СЕКРЕТАРЬ, реактивлар һәм җиһазлар җитештерү буенча ИНЖЕНЕР-ХИМИК, ТӘҖРИБӘЛЕ СТЕНОГРАФИСТКА һәм институт китапханәсенең чит телләр бүлегендә эшләү өчен, ЧИТ ТЕЛЛӘРНЕ БЕЛҮЧЕ РАБОТНИК. 35—3—3